Муниципальное автономное дошкольное образовательное учреждение
«Детский сад № 93 «Эллюки»
Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан

Рассмотрено и рекомендова
к утверждению на
педагогическом совете
протокол №2
от «27» августа 2020 года

Утверждено
Заведующий МАДОУ №93
_________ Г.И.Лотфуллина
приказ № 114
от «27» августа 2020 года

**УКЫТУ-ЭШ ПРОГРАММАСЫ**
**2020-2021 нчы уку елына мәктәпкәчә белем бирү**
**учреждениясенең төп бердәм укыту программасын тормышка ашыру**
**(кечкенәләр төркеме)**

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**
**по реализации основной общеобразовательной программы**
**дошкольного образовательного учреждения**
**на 2020 -2021 учебный год**
**(младшая группа)**

**Воспитатель:**
**Фатихова А.А.**

# ЭЧТӘЛЕК


| № п/п | Эш программасының структурасы | Битләр |
|---|---|---|
| | 1.МАКСАТЛЫ БҮЛЕК | |
| 1.1. | Аңлатма язуы | 3 |
| 1.2. | Эш программасының максаты, бурычлары | 3 |
| 1.3. | Эш программасының күрсәткече, юнәлеше | 3 |
| 1.4. | Балаларның яшь үзенчәлекләре | 5 |
| | 2. ЭЧТӘЛЕКЛЕ БҮЛЕК | |
| 2.1. | «Социаль коммуникатив үсеш» | 10 |
| 2.2. | «Танып белү үсеше» | 18 |
| 2.3. | «Сөйләм үсеше» | 24 |
| 2.4. | «Иҗади-эстетик үсеш» | 31 |
| 2.5. | «Физик үсеш» | 43 |
| | 3. ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ | |
| 3.1. | Көндәлек режим. | 50 |
| 3.2. | Тематик план. | 52 |
| 3.3. | Белем бирү эшчәнлегенең бер атнага төп төрләре исемлеге һәм саны. | 53 |
| 3.4. | Белем бирү эшчәнлеге челтәре. | 55 |
| 3.5. | Әти –әниләр белән эш. | 55 |
| | Кулланылган әдәбият исемлеге. | 56 |

## 1. МАКСАТЛЫ БҮЛЕК

### 1.1. Аңлатма язуы

4 нче кечкенәләр төркемендә эш программасы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының 93 нче номерлы «Әллүки «балалар бакчасы» һәм «Сөенче» (Р.К. Шәехов) мәктәпкәчә белем бирү региональ программасы нигезендә төзелгән.

Балалар бакчасының өстенлекле юнәлеше: «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның интеллектуаль-шәхси үсеше»

Эш программасы куллануга юнәлдерелгән:

1.Н.Е.Веракса, Т. С. Комарова, М. А. Васильева редакциясе астында «Мәктәпкәчә белем бирүнең» инновацион программасы;

2.Н.Е.Веракса, Т. С. Комарова, М. А. Васильева, 2 кечкенәләр төркем «мәктәпкәчә белем бирүнең» инновацион программасы буенча укыту-методик комплекты;

3."Сөембикә" мәктәпкәчә белем бирү региональ программасы (Р.К. Шәехов);

4.Төп юнәлешләр (мәгариф өлкәләре) буенча методик кулланмалар, дәресләр һәм авторлык эшләнмәләре конспектлары һәм сценарийлары)

### 1.2. Эш программасының максаты:

«Россия Федерациясе халыкларының рухи-әхлакый байлыклары, тарихи һәм милли-мәдәни традицияләр нигезендә гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү»

**Эш программасының бурычлары:**

1. Балаларның аң һәм физик үсешенең табигый процессына уен, аралашу, танып-белү, хезмәт, хәрәкәт, матур әдәбият уку, музыка- иҗат, ясау эшчәнлеге.
2. Белем өлкәләрен үзләштергәндә психологик һәм педагогик яктан ярдәм итү.
3. Режим моментларында, ирекле белем бирү , мөстәкыйль, ата-аналар белән эш вакытында зурлар-кечкенәләр бердәм (партнерлык) эшчәнлеген оештыру

Программа куйган максатларга ирешүдә түбәндәгеләр беренче әһәмияткә ия:

- балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;
- балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен киң куллану; укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү;
- тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;
- балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану; белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү (интегральләштерү);
- мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү оешмалары һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;
- гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм, гомумән, мәктәпкәчә оешма тормышында катнашуын тәэмин итү;
- балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага кирәгеннән артык акыл һәм физик эш йөкләмәү максатыннан дәвамчанлыкны саклау;
- региональ якын килүне гамәлгә ашыру.

**1.3. Эш программасының төп фикере** - укыту, тәрбияләү, сәламәтлеген саклау белән бергә баланың шәхесен үстерү.

**Эш программасының күрсәткече:**

*Балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып төп юнәлешләр – физик, социаль-коммуникатив, танып белү-сөйләм, иҗади-эстетик үсеш юнәлешләре буенча төрлеяклап үстерү;

*Балаларның иҗади сәләтен ачу, сәләтлеләрне табу, шәхси үстерү өчен яңа технологияләр куллану;

*Балаларның мөмкинчелегеннән, кызыксынучанлыгыннан, сорауларыннан чыгып төрле төр эшчәнлекләрне үстерү;

*Эчтәлекле аралашуга, сөйләшүгә төзелгән шәхси һәм төркем белән эшчәнлекләр оештыру;

*Балага эшчәнлектә үзен күрсәтү, эш эчтәлеген, эш төрләрен, эштә иптәш сайлау хокукы бирү.

**Эш программасы түбәндәге норматив документлар буенча яраклаштырылган:**

- Закон РФ «Белемалу турында» (ст. 32. п.2.7);
- Закон РТ «Белемалу турында»;
- «Татарстан Республикасында дәүләт телләрендә һәм Татарстан Республикасында башка телләрдә»;
- ФГОС ДО Россия Федерация Министрлыгында 2013 елның 14 ноябрендә N 30384 теркәлүендә теркәлде;
- Гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү өчен укыту программалары (Россия Федерациясе Мәгариф һәм Фән Министрлыгы боерыгы белән расланган 2013 елның 30 августы №1014) белән укыту чараларын оештыру һәм үткәрү тәртибе;
- 05.15.2013 санитар һәм эпидемиологик кагыйдәләр һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре өчен стандартлар 2.4.1.3049-13
- 93" балалар бакчасы «Эллюки» программасын эшләү кагыйдәләре

**Эш программасын тормышка ашыру срогы**- 1 ел (2020-2021 нчы уку елы)

**“Эллюки” исемле 93 нче балалар бакчасы турында гомуми белешм**

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының атамасы:**

Муниципальное автономное дошкольное образовательное учреждение «Детский сад №93 «Эллюки» является некоммерческой организацией в форме Учреждения и создана для обеспечения интеллектуального, личностного и физического развития детей, приобщения их к общечеловеческим ценностям, охраны жизни и укрепления здоровья детей.

**Кыскача атамасы** : “Эллюки” 93 нче балалар бакчасы МАДОУ

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының адресы:**

*субъект РФ:* Татарстан республикасы
*индекс*: 423678
*шәһәр:* Түбән Кама шәһәре
*урам:* Тынычлык
*йорт:* 113
*шәһәрнең федераль телефон коды:* (8555) *телефон:* 49-94-03
сайт: ds93bux@mail.ru

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының җитәкчесе:**

Лотфуллина Гелназ Илгизовна

**Балалар бакчасы эшчәнлегенең юнәлеше:**

1.Танып белү-сөйләм үсеше, социаль-коммуникатив үсеш, физик үсеш, иҗади-эстетик үсеш.

2.Мәктәптә укырга әзерләү (логик фикерләү, уку грамотасы.)

3.Сәламәтләндерү һәм профилактика чаралары

Балаларның танып-белү эшчәнлеген үстерү, тәрбия һәм белем бирү процессының сыйфатын яхшырту максатында балалар бакчасы үз алдына **түбәндәге бурычларны куя:**

1. Балаларның һәрьяклап үсешен тәэмин итү юнәлешендә яңа технологияләрне, үрнәк тәҗрибәләрне киң кулланып, балаларның сәламәтлеген саклау, аларны физик яктан ныгыту буенча нәтиҗәле эш алып баруны дәвам итү.

2. Балаларга тәрбия һәм белем бирү сыйфатын камилләштерү максатыннан чыгып, федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) таянып, алдынгы педагогик тәҗрибәләргә нигезләнеп, педагогларның һөнәри осталыгын үстерү һәм тәрбия-өйрәтү процессында информацион-компьютер технологияләрен куллану.

3.Балалар бакчасында бала шәхесен формалаштыруда гаилә белән бердәм эшчәнлек. Балалар бакчасы һәм гаилә арасындагы элемтәне халык педагогикасына, алдынгы гаилә тәҗрибәсенә таянып ныгыту, милли рухта мәхәббәт тәрбияләүгә юнәлтү.

4. “Татарстан Республикасы халыклары телләре” турындагы законны тормышка ашыруда яңа алымнарны куллану һәм укыту-методик комплекты аша балаларның сөйләмен сыйфатлы камилләштерүне дәвам итү

Балаларга белем һәм тәрбия бирү өчен түбәндәге кабинетлар эшләп килә: татар теле кабинеты, музыка һәм физкультура залы.

Бүгенге көндә балалар бакчасында 14 төркем.

**Балаларны балалар бакчасына кабул итү,тәрбия-белем бирү эшчәнлеген оештыру таләпләре. (СанПиН 2.4.1.3147-13).**

Балаларны иртән кабул итү тәрбиячеләр яки медицина хезмәткәрләре тарафыннан ата-аналардан баланың сәламәтлеген сораудан башлана. Күрсәткечләр буенча термометрия үткәрелә.Авыру, авыруга шик тудырган балалар бакчага кабул ителмиләр, көн дәвамында авыручыларны ата-аналары килгәнче яки ата-аналарга хәбәр итеп дәвалау оешмасына җибәргәнче башка сәламәт балалардан аералар. Авырудан соң һәм бала 5 көннән озаграк(бәйрәм, ял көннәреннән башка) килми торганнан соң балалар бакчасына авыруның диагнозы, авыру дәвамлыгы, йогышлы авырулар белән бәйләнеше булмау турындагы справка булганда гына кабул ителә.

Көн тәртибе балаларның яшь үзенчәлекләреннән чыгып төзелә һәм гармонияле үсешенә булыша. 3-7 яшьлек балаларның иң куп өзлексез уяну вакытының дәвамлыгы 5,5-6 сәгать. Тәкъдим ителгән көндәлек прогулкаларның дәвамлыгы-3-4 сәгать. Саф һавада булуның озынлыгы табигать шартларыннан да бәйле. Һава температурасы минус 15 °С түбән, җилнең тизлеге 7 м/с тан югары булганда саф һавада булу вакыты кыскартырга киңәш ителә.

Саф һавада йөрүне көнгә 2 тапкыр: көннең беренче яртысында һәм көннең икенче яртысында – көндезге йокыдан соң яки балалар өйгә кайтып китәр алдыннан тәкъдим ителә.

Балалар 5 сәгатьтән күбрәк булган мәктәпкәчә яшьтәге балалар оешмасында 3-4 сәгать аерма белән ашау һәм көндезге йокы оештырыла. Балаларның көнлек йокысы 12-12,5 сәгать булырга тиеш, шуның 2-2,5 сәгате көндезге йокыга бирелә. Йокы алдыннан хәрәкәтле уеннар, чыныктыру чаралары үткәрү тыела. Балалар йоклаганда тәрбиясенең (яки аның ярдәмчесе) булу мәҗбүри.

Көн тәртибендә 3-7 яшьлек балаларга мөстәкыйль эшчәнлек (уеннар, шәхси гигиена, уку эшчәнлегенә әзерләнү) өчен кимендә 3-4 сәгать вакыт бирелергә тиеш.

Балалар бакчасы 5 көнлек эш атнасында 6.00-18.00 сәгатькә кадәр эшли.

**1.4. 4 нчетөркем турында белешмә**

4 нче төркем – татар төркеме. Төркемдә 13 бала: 7 кыз һәм 6 малай йөри. Төркемдә 3-4 яшьлек балалар.

**4 нчы төркем балаларының яшь үзенчәлекләре.**

Бала үсешендә мәктәпкәчә яшь чоры күп төрле һәм дия намикалы булуы белән аерылып тора. Әлеге чор дәвамында төрле юнәлешләр буенча сизелерлек үзгәрешләр барлыкка килә. Уен, рәсем, төзү кебек эшчәнлек төрләре камилләшә. Безнең күз алдында 3—4 ел дәвамында балаларның игътибарры, хәтере, фикерләве, күзаллавы, сөйләме көчле үсеш ала. Гади җөмләләр катлаулылары белән алышына һәм кызыклы кечкенә хикәяләргә әверелә. Бу яшьтә баланың дуслары барлыкка килә башлый, ул һәм зурлар белән теләп аралаша, үз тәртибен көйли. Дөнья турында күзаллавы киңәя һәм «нигә?», «ни өчен?» сораулары җавап таләп итә. Мәктәпкәчә яшь чорының башы 3 яшьтәге кискен үзгәреш белән туры килә. Иртә яшьтә үсеш һәм тәрбия дөрес оештырылган булса, баланың 3—4 яшьтә буе 90—100 смга җитә, гәүдә авырлыгы якынча 13—16 кг була. Аның җитезлеге арта, тизрәк йөгерә, яхшырак сикерә, ыргыткан тупны ике кулы белән тотып ала. Әле 2 яшьтә ул бу хәрәкәтләрнең берсен дә эшли белми иде! 3—4 яшьтә балалар физик яктан көчлерәк, мөстәкыйльрәк. Физик тәрбия акыл тәрбиясе белән бәйләнештә алып барыла. Бу яшьтә акыл, эстетик, әхлак, физик үсеш югары темп ала. Мәктәпкәчә яшьтәге бала әйләнә-тирә дөньяны танып белә, күзәткән вакыйгаларны, күренешләрне аңларга тырыша. Дөрес оештырылган педагогик процесс нәтиҗәсендә балалар төрле төшенчәләрне үзләштерәләр, нәтиҗәләр чыгаралар, гомумиләштерәләр. Балаларның кызыксынучанлыгы, яхшы хәтере аңа күп информация тупларга ярдәм итә. Кызыксынучанлык баланы эзләнү эшчәнлегенә (Н.Н.Поддьяков), зурларга сораулар белән мөрәҗәгать итәргә стимуллаштыра. Сораулар характеры буенча баланың үсеш дәрәҗәсен билгеләргә була. 3—4 яшьлек баланың аралашуы гаилә белән генә чикләнми. Зурлар бала өчен гаилә әгъзасы гына түгел, ә билгеле иҗтимагый функция үтәүче булып та тора. Баланың шундый ук функция үтәргә теләве аның реаль мөмкинлекләре белән каршылыкка очрый. Әлеге каршылык» мәктәпкәчә яшьтә әйдәүче эшчәнлек — уен аша чишелә.

Уенның төп үзенчәлеге, аның шартлы рәвештә булуында. Кече мәктәпкәчә яшьтәге бала уенының төп эчтәлеген уенчыклар һәм предметны алмаштыра торган җиһазлар тәшкил итә. Бу яшьтә балаларның уены озак вакытка сузылмый. Кече мәктәпкәчә яшьтәге балалар уенда берике роль һәм гади сю-жетлар белән чикләнәләр. Кагыйдәле уеннар әле формалаша гына башлый.

3-4 яшьлек балаларның эшчәнлеге катлаулана һәм төрлеләнә: алар уку һәм хезмәт биремнәрен уеннар аера башлыйлар. Уен һәм шөгыль нәтиҗәсендә психик процесслар (хәтер, фикерләү, игътибар, күзаллау) үсеш ала, балаларның яңа ихтияҗлары һәм мәнфәгатьләре барлыкка килә.

Информатив, катлаулы һәм күләмле күрсәткеч булып акыл үсеше тора. Киң мәгънәдә акыл үсеше төп танып белү про-цессы үсеше буларак аңлатыла. Тар мәгънәдә — акыл сәләте үсеше. Акыл сәләте үсеше баланың әйләнә-тирәдә ориентирлашу ысулларын гомумиләштерүне күз алдында тота.

3-4 яшьлек балалар үсешендә сәнгать эшчәнлеге мөһим урын алып тора. Әлеге эшчәнлек баланың предмет турындагы күзаллауларына бәйле. Бу яшьтә күзаллаулар формалаша гына башлый. График образлар ярлы. Кайбер балаларның рәсемнәрендә детальләр төшеп кала, ә икенчеләре киресенчә, җентекләп ясый. Балалар рәсемнәрдә төрле төсләр куллана башлый. Кул моторикасын үстерү өчен әвәләү, бармаклар гимнастикасы зур әһәмияткә ия. Кече мәктәпкәчә яшьтәге балалар зурлар җитәкчелегендә гади предметлар әвәләргә сәләтле. Кисеп ябыштыруның (аппликация) кабул итү үсешенә уңай йогынты ясавы билгеле. Бу яшьтә кисеп ябыштыруның иң гади төрләрен башкаралар.

Кече мәктәпкәчә яшьтә балаларның төзү эшчәнлеге, үрнәк буенча һәм уйлап чыгарылган катлаулы булмаган төзелешләр белән чикләнә.

Әлеге яшьтә аерым эшчәнлекләр үсеш ала. Балалар башлангыч эталоннарны (кабул итүнең индивидуаль берәмлекләре) кулланудан сенсор эталоннарга (кабул итүнең эшкәртелгән чаралары) күчәләр. Кече мәктәпкәчә яшь ахырына балалар предметларның һәм төсләрнең биштән алып җиде төренә кадәр аералар, предметларны зурлыгы буенча дифференциациялиләр, балалар бакчасының төркем бүлмәсе, белем бирү процессын оештырганада, бөтен балалар бакчасы бинасы пространствосында ориентирлашалар.

Хәтер һәм игътибар үсеш ала. Зурлар үтенече буенча балалар 3-4 сүз һәм 5-6 предмет исемен хәтерләрендә калдыралар. Кече мәктәпкәчә яшь ахырына алар яраткан әсәрләрдән өзекләрне истә калдырырга сәләтле. Күрсәтмә-хәрәкәт фикерләве үсеше дәвам итә. Шуның белән беррәттән, кайбер очракларда, теләгән нәтиҗәләрне исәпкә алып, мак-сатчан үрнәк нигезендә ситуация үзгәрә. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар предметлар арасындагы кайбер яшерен бәйләнешне билгеләргә сәләтле. Кече мәктәпкәчә яшьтә күзаллау үсеш ала һәм ул бигрәк тә уенда чагылыш таба. Балалар арасындагы үзара мөнәсәбәт нормалар һәм кагыйдәләр белән билгеләнә. Максатчан тәэсир итү нәтиҗәсендә, алар үзләренең һәм башка балаларның эшләрен бәяләү өчен ни-гез булган, чагыштырмача зур күләмдә нормаларны үзләштерә алалар. Балалар арасындагы үзара мөнәсәбәт бигрәк тә уем эшчәнлегендә ачык чагыла. Шулай ук бу яшьтә сайлауга корылган үзара мөнәсәбәт тә күзәтелә.

**Гомуми исемлек**

| № п/п | Баланың исеме, фамилиясе |
|---|---|
| 1. | Агидуллин Аскар |
| 2. | Агиев Тимур |
| 3. | Ахбаев Салават |
| 4. | Билалова Асиля |
| 5. | Габдрахимов Арслан |
| 6. | Габдуллина Рубина |
| 7. | Галиев Талгат |
| 8. | Галимова Айлина |
| 9. | Гараева Лия |
| 10. | Ермилов Наиль |
| 11. | Иванова Милана |
| 12. | Идиятуллина Иделия |
| 13. | Курмаева Александра |
| 14. | Мавлявиев Булат |
| 15. | Мавлявиев Тимур |
| 16. | Маслахова Саида |
| 17. | Насыбуллина Риана |
| 18. | Фатхиев Тимур |
| 19. | Фатыхова Айвиля |
| 20. | Хуззатуллина Ралина |

| | |
|---|---|
| 21. | Хурматуллин Камиль |
| 22. | Шавалиева Радмила |

## СОЦИАЛЬ-ПЕДАГОГИК ПАСПОРТ

4 нче кечкенәләр төркеме МАДОУ №93 (сентябрь 2020 г.)

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Торкемдэ балалар саны: | 22 |
| 2. | Аз керемле гаилә балалары: | |
| 3. | бер ата-ана (ялгыз)булган балалар: | 1 |
| 4. | Тулы булмаган гаилә балалары (аерылышуда): | 1 |
| 5. | Күп балалы гаилә балалары: | 3 |
| 6. | Опекага алынган балалар | 1 |
| 7. | Ятим балалар: | - |
| 8. | Инвалид балалар: | - |
| 9. | Социаль имин булмаган гаиләләрдәге балалар: | - |
| 10. | Качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр гаиләләреннән балалар: | - |
| 11. | Хәрби хезмәткәрләр гаиләсеннән балалар: | 3 |
| 12. | Гаилэдэ 1 нче бала: | 3 |
| 13. | Гаилэдэ 2 нче бала: | 17 |
| 14. | Гаиләдә өченче һәм аннан соңгы бала: | 3 |
| 15. | 3 яшькэ кадэр балалар | |
| 16. | 3 яшьтэн 5 яшькэ кадэр | |
| 17. | 5 яшьтэн 7 яшькэ кадэр | |

Гаиләләр турында соиологик белешмәләр

| | | |
|---|---|---|
| | Төркемдә балалар саны<br>Алардан | 22 |
| | Малай | 10 |
| | Кызлар | 12 |
| | Тулы гаилә | 21 |

| | | |
|---|---|---|
| | Тулы булмаган гаилэ | 1 |
| | Бер балалы гаилэлэр | 1 |
| | Ике баласы булган гаиләләр | 17 |
| | Өч һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләр | 4 |
| | Эшләүче әниләр | 19 |
| | Эшләмәүче әниләр , д / о | 2 |

Куп балалы гаилә балалары

| № | Баланын исем,фамилиясе | Туган көне |
|---|---|---|
| 1. | Агидуллин Аскар | 19.12.16. |
| 2 | Габдрахманов Арслан | 11.04.17. |
| 3 | Хурматуллин Камиль | 28.02.17. |

**2. ЭЧТӘЛЕК БҮЛЕГЕ**

## 2.1. «СОЦИАЛЬ-КОММУНИКАТИВ ҮСЕШ»

***Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйльлек***

***Аңлатма язуы***

«Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйльлек» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татар халык әкиятләре ярдәмендә хезмәт эшчәнлеге турында күзаллаулар формалаштыру. Баланың эш барышын татар шагыйрьләренең хезмәт турындагы шигырьләре белән бәйләү.

Балаларга аңлаешлы һөнәрләр (төзүче, электрик, сантехник һ. б.) белән таныштыруны дәвам итү. Өлкәннәрнең хезмәт чичәнлегенең мәгънәсе турында күзаллаулар формалаштыруХезмәт эшчәнлегенең төп бурычы булып тора. Бу бурычны тормышка ашыру түбәндәге мәсьәләләрне чишү аша башкарыла:

- зурлар хезмәте белән танышу, хезмәтнең җәмкыятькә кирәклеге һәм файдасы турында күзаллауларын формалаштыруҺәм кеше хезмәтенә хөрмәт, хезмәтнең нәтиҗәсенә сак караш тәрбияләү;
- балаларның хезмәт эшчәнлеген оештыру, эш тәҗрибәсе , эшне оештыру, зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара уңай мөнәсәбәтләр урнаштыру күнекмәләрен камилләштерү.

***Комплекслы - тематик план***

| Ай | Атна | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | «Аю өне янында»<br>«Бүре һәм куяннар» | Сикерү күнекмәләрен үстерү, сыгынучанлыкны, җитезлекне булдыру, сиганал буенча хәрәкәтләрне төгәл башкарырга өйрәтү. |
| | II | «Светофор һәм автомобиль» | Бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. Юлдагы куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. |
| | | «Трамвай" | Игътибарлыкларын тупларга күнектерү, түземлек тәрбияләү, уен кагыйдәсен үтәргә өйрәтү. |
| | III | «Огуречик»<br>"Көтүче һәм көтү" | Йөгерү тизлеген үстерү,сигнал буенча хәрәкәт итү,шигырь сүзләренә туры китереп уйнау, күзәтүчәнлекне үстерү. |
| | IV | «Песи һәм тычканнар», | Пространствода ориентлашу, бәрелми – төртелми уйнауны булдыру. |
| | | "Очкычлар" | Төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен системалаштыру, дус –тату уйнауны булдыру. |
| Октябрь | I | "Ябалак" | Игътибарлылык, кыюлык, җитезлек кебек матур сыйфатлар тәрбияләү, шигырь сүзләренә туры китереп уйнау. |
| | | "Төсле автомобильләр" | Юл йөрү кагыйдәләрен ныгыту, төсләр турында белемнәрен камилләштерү, сиганал буенча хәрәкәтләнүне булдыру |
| | II | «Кыршау эченә ыргыт» | Дус – тату уйнауны булдыру, туп ыгргыту, төгәллек сыйфатлары тәрбияләү |
| | | "Инеш аша сикереп чык" | Урыннан 2 аякта ераклыкка сикерү күнекмәләрен камилләштерү, кыюлык тәрбияләү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | «Бау аша сикер», | Сикерү күнекмәләрен камилләштерү, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| | | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту. |
| | IV | “Төсле автомибильләр” | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |
| | | “Аю-бүре” | Йөгереклек һәм җитезлек сәләтен үстерү,сүзләргә туры китереп хәрәкәтләр ясау. |
| ноябрь | I | “Казлар - аккошлар” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | “Сиздермичә йөгереп үт” | Сизгерлек булдыру, дус –тату унарга өйрәтүне дәвам итү. |
| | II | «Төлке һәм тавыклар», | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү. |
| | | “Үз төсеңне тап” | Хәтерне, җитезлекне үстерү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга өйрәтүне дәвам итү, кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| | III | «Мин качам, син тот», | Коллективта бергә уйнау теләге уяту, пространствода ориентлашу булдыру, сигналларга игътибар итү, ишетү сәләтен үстерү. |
| | | «Светофор һәм автомобиль» | Бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. Юлдагы куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. |
| | IV | «Аучылар һәм куяннар» | Тупны ыргытырга,дус һәм тату уйнарга өйрәтү, җитезлекне үстерү. |
| | | “Әбәкле” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| декабрь | I | “Песи һәм кошчыклар” | Хәрәкәт координациясен, җитезлекнее үстерү, уен белән кызыксындыру булдыру. |
| | | «Кемдә йөзек?» | Халык уеннарына карата кызыксыну уяту, хәрәкәт активлыгын үстерү. |
| | II | “Кем беренче?” | Йөгерү тизлеген үстерү, максатка ирешүчәнлек кебек яхшы сыйфатлар тәрбияләү. |
| | | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү |
| | III | «Куяннар һәм төлке» | Сабырлык, җитезлек, хәрәкәт активлыгы тәрбияләү, пространствода оринтлашу булдыру, рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен үстерү. |
| | | “Кегляны аудар” | Төзлекне, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | «Балалар һәм этәч» | Җитезлекләрен үстерү, бер –бер артлы йөгерү күнекмәләрен булдыру**.** |
| | | “Тавык кетәклегендә төлке” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү. |
| январь | I | «Куяннар һәм төлке” | Сабырлык, җитезлек, хәрәкәт активлыгы тәрбияләү, пространствода оринтлашу булдыру, рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен үстерү |
| | | “Кем беренче?” | Йогерү тизлеген үстерү, максатка ирешү сыйфатын тәрбияләү. |
| | II | “Энә һәм җеп” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, бер-бер артлы йөгерү күнекмәләрен үстерү. |
| | | “Бүре һәм сакрыклар” | Түгәрәккә басарга, күмәк уйнарга, хәрәкәтләрне дөрес итеп башкарырга күнектерүне дәвам итү. |
| | III | “Оядагы кошлар” | Сизгерлек, сигнал буенча хәрәкәт итү күнекмәләрен тәрбияләү. |
| | | “Үз парыңны тап” | Төрле юнәлештә йөгереп, сигнал булгач, үз парыңны табу күнекмәләрен үстерү, дус – тату уйнауны булдыруны дәвам итү. |
| | IV | “Кем беренче?” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| февраль | I | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү. |
| | | “Кегляны аудар” | Төзлекне, тырыщ, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |
| | II | “Төлке килә” | Сигнал буенча хәрәкәтләнү күнекмәләрен камилләштерү, сизгерлекләрен үстерү. |
| | | «Ак, димә, кара, димә» | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | III | “Чаналар белән ярыш” | Җитезлекне, тизлекне булдыруны дәвам итү, дус –тату уйнау теләкләре тудыру. |
| | | “Соры бүре” | Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру. |
| | IV | “Кошлар очалар” | Хәрәкәт тизлеген үстерүне дәвам итү, төрле юнәлештә очу күнегүләрен башкарып йөгерү, сигналларга игътибар итүне булдыру. |
| | | «Эстафета» | Йөгерү тизлеген үстерүне дәвам итү, бер – бер артлы сигнал буенча йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| мар т | I | «Тупны ыргыт» | Төзлекне, тырыщ, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| | II | “Инеш аша сикереп чык” | Урыннан 2 аякта ераклыкка сикерү күнекмәләрен камилләштерү, кыюлык тәрбияләү. |
| | | “Үрдәк атыш” | Тупны тотарга, туптан качарга өйрәтүне дәвам итү, төз атуны булдыру, балаларның хәрәкәтчәнлекләрен, җитезлекләрен үстерү. |
| | III | «Кармак» | Сикерү күнекмәләрен үстерү, сыгынучанлык, чыдамлылык булдыру, бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | | «Буяучы һәм буяулар», | Йөгерү тизлеген үстерү, пространствода ориентлашу күнекмәләрен, төсләр турында белемнәрен камилләштерүне дәвам итү. |
| | IV | “Үз парыңны тап” | Төрле юнәлештә йөгереп, сигнал булгач, үз парыңны табу күнекмәләрен үстерү, дус – тату уйнауны булдыруны дәвам итү. |
| | | “Кармак” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| апрель | I | “Бүре һәм сакрыклар” | Түгәрәккә басарга, күмәк уйнарга, хәрәкәтләрне дөрес итеп башкарырга күнектерүне дәвам итү. |
| | | “Тупны тәгәрәт” | Тупны предметлар аша тәгәрәтү, максатка ирешүчәнлек, башлаган эшне азагына кадәр эшләп чыгу күнекмәләрен үстерү. |
| | II | “Челән белән бакалар” | Сикерү тизлеген үстерү, сигнал буенча хәрәкәт итү, пространствода ориентлашу, тизлек булдыруны дәвам итү. |
| | | “Флагка кадәр йөгер” | Йөгерү тизлеген үстерүне дәвам итү, бер – бер артлы сигнал буенча йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | “Тавык кетәклегендә төлке” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү өстендә эшне дәвам итү. |
| | | “Әбәк” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | IV | “Бал кортлары” | Йөгерү күнекмәләрен үстерүне дәвам итү, пространствода ориентлашуны камилләштерү. |
| | | «Идәндә калма», | Сикерү күнекмәләрен камилләштерү, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| май | I | «Каршылыклар юлы» | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Тупны, сикертеп, алып бар” | Тупны сикертеп алып барырга өйрәтә башлау, максатчанлык, батырлык сыйфатлары тәрбияләү. |
| | II | «Трамвай” | Игътибарлыкларын тупларга күнектерү, түземлек тәрбияләү, уен кагыйдәсен үтәргә өйрәтү. |
| | | “Буш урын” | Күзәтүчәнлекләрен, игътибарлыкларын үстерү, этешми-төртешми уйнау күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | “Бал кортлары” | Йөгерү күнекмәләрен тәрбияләү. |
| | | «Кем тизрәк?» | Төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен системалаштыру, дус –тату уйнауны булдыру. |
| | IV | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| | | “Соры бүре” | Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру. |

**Социализацияләштерү, аралашу усеше, әхлаклы тәрбия. Бала гаиләдә һәм җәмгыятьтә**

***Аңлатма язуы***

«Социализацияләштерү, аралашу усеше, әхлаклы тәрбия. Бала гаиләдә һәм җәмгыятьтә» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү ьәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә нәм белем бирү бурычларын билгели.

Туган телдә аралашырга теләкләрен хуплау; башка кешеләр белән аралашканда, аларның тәкъдимнәренә әдәпле итеп җавап бирү; төрле эшчәнлек төрләрендә өлкәннәр һәм балалар белән телдән һәм телдән булмаган бәйләнешләр урнаштыру.

Әйләнә-тирә, туган шәһәр (авыл), республика вакыйгалары турында әңгәмәләрне хуплау.

Аралашу культурасы формалаштыру (сөйләшүченең милләтенә карап, ачык йөз күрсәтеп, шул телдә исәнләшү һәм саубуллашу; үтенеч һәм тәкъдимнәр белән ягымлы итеп мөрәҗәгать итү; күрсәткән хезмәте, ярдәме, сый-хөрмәте өчен рәхмәт белдерү).

Балаларны ил, республиканың күренекле төп бәйрәмнәрен билгеләп үтәргә өйрәтү. Балалар оешмасы, республика, ил тормышына баланың мөнәсәбәте, катнашы булуына ирешү.

Өлкәннәр һәм яшьтәшләре (өч-дүрт бала) белән күмәк уеннарда катнашуга теләк уяту; әйләнә-тирәдәге тормыш, халыклар яшәеше темасына татар язучылары һәм шагыйрьләренең әдәби әсәрләре, мультфильмнар буенча, уен өчен катлаулы булмаган сюжетлар тәкъдим итү.

Уендагы иптәшләр арасында рольләрне бүлә белергә, уен өчен кирәкле өй кирәк-ярагы (көянтә-чиләкләр, казан, уклау һ. б.), милли костюм, ювелир (зәркән) бизәнү әйберләре, читекләр һ. б., милли уенчыклар, музыка уен кораллары сайларга һәм аларны рольгә туры китереп файдаланырга өйрәтү.

Милли киемдәге курчакларны, образлы уенчыкларны, бибабо, кулдан ясалган уенчыклар һәм кайбер сәнгатьлелек чараларын, кул хәрәкәтләре, мимика, интонация кулланып, театральләштерелгән һәм режиссер уеннарында катлаулы булмаган сюжетлар буенча (татар халык әкиятләре буенча куелган мультфильмнардан) ситуацияләрне уйнап күрсәтү.

Баланың үзе, әти-әнилөренең милләте турындагы күзаллавын формалаштыру. Гаилә рәсемнәрен караганда, әти-әниләре белән охшаш чалымнары булуына игътибар итү. Фото- сурәттәге кешеләрнең эмоциональ халәтен билгеләргә, аларның кәефләрен гаилә тормышындагы билгеле бер вакыйга белән бәйләргә өйрәтү.Гаилә турында һәм үзенең шул гаилә әгъзасы булуы турында; гаиләнең барлык әгъзаларының һәм баланың үзенең бурычлары, мавыгулары, яллары турында; гаилә гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәренең матурлыгы һәм әһәмияте турында күзаллаулар формалаштыру. Гаилә истәлекләренә сакчыл караш тәрбияләү.

***Сюжетлы – ролле уеннар***

***Комплекслы – тематик план***

| **ай** | **атна** | **Эшчәнлек темасы** | **Эшчәнлек эчтәлеге** | **Бурычлар** |
|---|---|---|---|---|
| сентябрь | I | “Гаилә” | Әни кызын ашата, йокларга яткыра. Д./уен «Курчакны сыйлыйк», «Курчакны йокларга яткырыйк» | Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү,уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | | “Мин сатучы” | Әни кызы белән кибеткә килә, азык-төлек ала. Сатучы товар сата, үлчәүдә үлчи. | |
| | II | “Парковка” | Юлда машиналар йөри, юл йөрү кагыйдәләрен үтеп машиналарны урыннарга куялар. | |
| | | “Коткару хезмәте” | Коткару хезмәте кешеләре авыр очракларда ярдәмгә ашыгалар: пожар, юлларда хәләкәт. | |
| | III | «Яшелчәләр кибете» | Әни кызы белән кибеткә килә, азык-төлек ала. Сатучы товар сата, үлчәүдә яшелчә үлчи.Д/уен “Яшелчә кибетендә ниләр сатыла”. | |
| | | «Көзге ярминкә» | Көзге ярминкәгә киләләр, яшелчә, җиләк-җимеш сатып алалар, хакларын очсызлаталар. | |
| | IV | “Даруханә” | Даруханәгә киләләр, нәрсә авыртканын әйтәләр, кирәкле дару сатып алалар. | |
| | | «Шифаханә» | Әни кызын врачка алып килә. Врач авыруларны кабул итә, нәрсә авыртканын сорый, тыңлый, дәвалау билгели.<br>Медкабинетка экскурсия. | |
| ок тя бр | I | «Гаилә» | Әни юа, кием үтүкли, бүлмә җыештыра. Д./уен «Курчакның күлмәген үтүклик, бездә тәртип» | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | II | «Балалар бакчасы» | Балалар бакчага килә, анда музыка, физкультура белән шөгыльләнәләр.Рәсемнәр карау. | |
| | III | «Гаилә» | Әни кызын ашата, йокларга яткыра, бишек җырлары җырлый. Уку: бишек җырлары. | |
| | IV | Транспорт» | Шофёр курчакларны машинага утыртып йөртә, төзү әйберләре ташый. Әңгәмә: “Машиналар урамда ничек йөри” | |
| ноябрь | I | Төзелеш» | Төзүчеләр машиналарга гараж төзиләр, уенчыкларга йорт, төзелеш коралларын кулланалар. Төзү материалларының детальларын карау. | |
| | II | «Йөртүчеләр һәм җәяүлеләр | Машиналар һәм җәяүлеләр юл йөрү билгеләрен үтәп эшкә баралар. Дидактик уен “Юл йөрү билгеләре” | |
| | III | «Чәчтараш» | Чәчтарашка балалар әниләре белән киләләр. Парикмахер чәч тарый һәм ала. Дидактик уен “Чәчтараш җиһазлары” | |
| | IV | «Гаилә» | Курчакның туган көне. Кунаклар чакырабыз, сыйлыйбыз.<br>Әңгәмә «Бүген кемнең туган көне?» | |
| декабрь | I | «Кафе» | Кафега киләләр, алар туңдырма ашыйлар, сок эчәләр. Официант заказ кабул итә һәм сораган әйберләрне китерә.<br>Дидактик уен «Без кафега килдек» | Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнүне дәвам итү, балаларны уенчыклар белән сакчыл уйнарга өндәү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга, кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| | II | «Поликлиника» | Медсестра прививка ясый, витаминнар тәкъдим итә.<br>Шәфкать туташы эшен күзәтү. | |
| | III | «Транспорт» | Балалар шәһәр буйлап экскурсиягә чыгалар, бәйрәмгә бизәлгән урамнарны карыйлар. Рәсемнәр карау. | |
| | IV | «Гаилә» | Әни кызы белән чыршы бизи, кунаклар каршы ала.Уку<br>О. Высотская «Ёлочка».<br>Дидактик уен «Акбайга кунаклар каршы алуны күрсәтик» | |
| январь | I | «Чәчтараш» | Чәчтарашка балалар әниләре белән киләләр. Парикмахер чәч тарый һәм ала. Дидактик уен “Чәчтараш җиһазлары” | |
| | II | «Шифаханә» | Кызы авыргач әнисе аны поликлиникага алып бара, врачка күрсәтә.<br>Әңгәмә «Әгәр берәрсе авырса нишләргә” | |
| | III | “Театр” | Балалар театрга баралар, билетлар алалар, театр күрсәтәләр. Әңгәмә “Театр төрләре” | |
| | IV | «Транспорт» | Кунакка поездда баралар. Пассажирлар билет сатып алалар. Рәсемнәр карау. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| февраль | I | «Гаилә» | Курчакларны киендереп урамга чыгалар. Урамда балалар белән коляска йөртүче әниләрне күзәтәләр.<br>Дидуен «Курчакны йөртәбез» | |
| | II | “Коткару хезмәте” | Коткару хезмәте кешеләре авыр очракларда ярдәмгә ашыгалар: пожар, юлларда һәлакәт, җир тетрәү. | |
| | III | “Машинаны төзәтәбез” | Машиналарны төзәтүче янына алып киләләр, төзәтүче машиналарны карый, төзәтә. | |
| | IV | “Автобус” | Балалар автобус тукталышында торалар, автобуска утыралар, билет алалар. Әңгәмә “Җәмгыять транспортында үзеңне тоту кагыйдәләре” | |
| март | I | “Мин сатучы” | Әни кызы белән кибеткә килә, бәйрәмгә азык-төлек ала. Сатучы товар сата, үлчәүдә үлчи. Әңгәмә “Сатучы һөнәре” | Рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен камилләштерү,балаларның дуслык турында мәгълүматларын тулыландыру, әләкләшүнең начар гадәт икәнен, дусларыңны уңайсыз хәлгә куярга ярамаганлыгын төшендерү. |
| | II | “Гаилә” | 8март бәйрәме: бүләкләр алу, үз кулларың белән әниләргә, әбиләргә бүләкләр ясау, өстәлне бәйрәмгә әзерләү.“Ләйлә шигырен уку, “Минем әнием” әңгәмә. | |
| | III | “Гаилә” | Курчакның киемнәрен юалар, үтәклиләр, киптерергә эләләр. Әңгәмә “Кием төрләре” | |
| | IV | «Цирк» | Балалар циркка баралар, билетлар алалар, клоуннар тамаша күрсәтә. | |
| апрель | I | “Янгын сүндерүчеләр” | Янгын сүндерүчеләр чакыруга килә, янгын сүндерә, беренче ярдәм күрсәтә, кисәтә. Дидактик уен “Азбука пожарных”, “Не играй с огнем”. Уку С. Маршак «Кошкин дом», «Пожар». | |
| | II | “Почта” | Кешеләр бер-берсенә хатлар язалар, телеграмма, посылка җибәрәләр. Почта ташучы аларны адреслар буенча тапшыра. Почтадан җибәрелгән әйберләрнең рәсемнәрен карау. Дидактик уеннар һәм күнегүләр: «Дустыма хат», «Минем адрес» | |
| | III | “Телефон салоны” | Балалар телефон салонына киләләр, телефоннар һәм фотоаппаратлар карыйлар, сатып алалар. Әңгәмә “Телефон ни өчен кирәк?” | |
| | IV | “Төзелеш” | Төзүчеләр киләләр, төзелеш өчен план алалар, күп машиналар өчен зур гараж, өйләр төзиләр, төзелеш объектларын тапшыралар.Рәсемнәр карау. Якын тирәдәге объектларны күзәтү. | |
| май | I | “Уенчыклар кибете” | Сатып алучылар уенчык сайлыйлар, сатучы белән киңәшәләр, кассага акча түлиләр, чекларны сатучыга бирәләр. Сатучы сатып алучылар белән әдәпле итеп сөйләшә, аларга төрле уенчыклар тәкъдим итә, аларның ни өчен яхшы булуын сөйли, уенчыкны бирә, сатып бирә. Әңгәмә “Әдәпле сатып алучылар”. Дидактик уен: «Уенчыкны тасвирла», «Нәрсә үзгәрде», «Тасвирлау буенча тап». | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | II | “Гаилә” | Җиңү бәйрәме: бүләкләр алу, үз кулларың белән бабайларга, әбиләргә бүләкләр ясау, өстәлне бәйрәмгә әзерләү. Әңгәмә “Җиңү бәйрәме” | Рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен ныгыту, һөнәрләрнең кирәк-яраклары турындагы белемнәрен үстерү, диалог корып сөйләшү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | “Транспорт” | Йөк һәм җидел машиналар урамда йөри, җәяүлеләр тротуардан баралар, җәяүле чыгу урыныннан юл аркылы чыгалар, бетенесе дә юл йөрү кагыйдәләрен үтиләр.Светофорга, көйләнелми торган юл чатына максатлы сәяхәт.Дидактик уен: «Ихтибар, җәяүле», «Кызыл, сары, яшел» | |
| | IV | “Кибет” | Төрле бүлекләре (табак-савыт, йорт җиһазлары, язу-сызу әйберләре h.б.) булган яңа супермаркет ачылды. Сатып алучылар әйбер сайлыйлар, сатучыдан алар турында сөйләвен сорыйлар ( төсе, материалы, кулланылышы. | |

**2.2. «ТАНЫП БЕЛҮ ҮСЕШЕ»**

***ӘЙЛӘНӘ- ТИРӘ БЕЛӘН ТАНЫШУ***

***Аңлатма язуы***

Балаларны балалар бакчасында ориентлашырга өйрәтү, үз туган җире, шәһәре турында белемнәрен үстерү.

Балаларны өлкәннәр( шәфкатьтуташы, пешекче) хезмәте белән таныштыруны дәвам итү, аларның игътибарын бу хезмәт кешеләренең эшенә һәм эшнең нәтиҗәсенә юнәлтү.Өлкәннәр хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.

Предметларны кулланылышы, төсе, формасы, материалы буенча чагыш- тыру һәм төркемләргә өйрәтү. Гомумиләштерүче сүзләрнең (уенчык,кием- салым, аяк киеме, җиһаз, савыт-саба) мәгънәсен аңлату.

Балаларны агачның кәүсәсен, ботакларын, яфракларын; үләнчел үсемлек-ләрнең сабак, яфрак, чәчәкләрен таный һәм әйтеп бирергә өйрәтү.

3-4төрле яшелчә һәм җиләк- җимешне танырга өйрәтү, йорт хайваннары һәм кыргый хайваннар турында күзаллау булдыру. Җир-су хайваннары белән таныштыру.Табигатьтә аларның әһәмиятен аңлату.

Балаларны төзелгән корылмаларга гади анализ ясарга өйрәтү,конструктор- лык осталыкларын камилләштерү. Корылманың өлешләрен зурлыклары бу- енча (зур- кечкенә, озын- кыска, биек- тәбәнәк, тар- киң) аера һәм әйтеп бирә белергә өйрәтү. Балаларның үзләре уйлаганча төзү теләген үстерү.

Балаларның логик фикерләвен,игътибарын һәм хәтерләрен үстерү.

Күплек, сан, зурлык, форма,тирәлек һәм вакыт төшенчәләре турында белем бирү, санау, исәпләү, үлчәү,төзү күнекмәләрен формалаштыру; мате- матик мәсьәләләр чишкәндә ихтыяр көче, мөстәкыйльлек тәрбияләү.

***Комплекслы – тематик план***

***ӘЙЛӘНӘ- ТИРӘ БЕЛӘН ТАНЫШУ***

| Ай | № | Тема | Максат |
|---|---|---|---|
| се нт | 1. | Исәнмесез! | Исәнләшү,аралашу,үз-үзләрен тотуның иң гади кагыйдәләре белән таныштыру; зурлар һәм иптәшләре белән аралашу күнекмәләрен үстерү,әдәплелек,әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2. | Көз безгә нәрсәләр бүләк итте? | Ел фасыллары турындагы белемнәрен киңәйтү; көз фасылларының төп билгеләре ( көн болытлы, вак яңгыр ява, яфрак коела,көннәр суыта) турында белемнәрен үстерү. |
| | 3. | Сап-сары яфраклар өзелеп төшә җиргә. | Көзге агачларга хас булган билгеләр , чәчәкнең төзелеше: тамыр, сабак, яфрак, чәчәк таҗлары белән таныштыру; табигатькә мәхәббәт, кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | 4. | Безнең бүлмәдәге уенчыклар. | Төркемдәге уенчыкларның исемнәре белән таныштыру, аларны ни өчен кирәк булуына, төсенә, формасына карап төркемнәргә аеру; уен- чыклар белән сак уйнарга, дус, тату булырга өйрәтү. |
| октябрь | 1. | Төркемебезнең куркынычсызлыгы. | Төркем турындагы белемнәрен ныгыту; ориентлашу күнекмәләрен үстерү, төркемдә булган әйберләргә сак караш тәрбияләү. |
| | 2. | Кояш кайда йоклый? | Тере булмаган табигатькә:кояш,ай, йолдызларга карата кызыксыну уяту; табигатьтә булган бәйләнешләр( кояш бул са-көн, ай һәм йолдызлар – төн җитә) турындагы белемнәрен үстерү, киңәйтү. |
| | 3. | Песи һәм песи баласы. | Йорт хайваннары һәм алар ның балалары белән таныш тыру; балаларының исемнәрен истә калдыру;йорт хайваннарына карата мәхәб бәт тәрбияләү,алар турында кайгырту. |
| | 4. | Җиләк-җимешләр. | Җиләк- җимешләр турындагы белемнәрен ныгыту,алардан нинди ризыклар әзерләп бу луы турында фикер алышу; кунакчыллык сыйфатлары тәрбияләү, төрле эшләрдә өлкәннәргә булышу теләге уяту. |
| ноябрь | 1. | Минем әти, минем әни. | Гаилә турында күзаллау үстерү,гаилә әгъзаларын атый белергә өйрәтү,якыннарга карата ярату,кайгырту хисләре тәрбияләү. |
| | 2. | Җил. | Табигатьтәге бәйләнешне( көз җитү, кояш җылыта,көчле җил исә, агачлардан яфраклар коела) күрә белергә өйрәтү. Ишетү һәм күрү сәләтен үстерү. |
| | 3. | Җәнлекләр кышка ничек әзерләнә? | Табигатьтәге сезонлы үзгә решләр арасындагы гади бәйләнешләрне билгеләргә өйрәтү;җәнлекләрнең үз-үзләрен тотышы, балалары турындагы белемнәрен үстерү.Игътибарлылык, дус танә мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | 4. | Төшке ашка безгә нәрсә? | Табак- савытларны кулланы шы ягыннан бүләргә өйрәтү (төсе,формасы ,зурлыгы). Үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен өйрәтүне дәвам итү. |
| декабрь | 1. | Электр лампасы белән таныштыру. | Электр турында балаларга гади төшенчә бирү; балаларның игътибарын, хәтерен,кабул итү сәләтен үстерү;ток белән бәйләнешле булган куркынычсызлык кагыйдәләрен балаларга җиткерү, сакчыллык тәрбияләү. |
| | 2. | Гирлянда. | Балаларга гирлянда турында башлангыч белемнәр бирү, электр тогы турында күзал лауны ныгыту; төсләрне таный һәм аера белергә күнектерү; кызыксынучанлыкны үстерү, сүз байлыгын киңәйтү. |
| | 3. | Яшел чыршы. | Балалар белән бергәләп чыршыны карау.Яңа ел бәй рәме турында күзаллауларын киңәйтү; матурлыкны күрә һәм аңа карап соклана белү хисләре, чыршы уенчыклары на карата сакчыл караш тәр бияләү;сүз байлыгын үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 4. | Чыршы бизибез. | Балаларның бәйрәм турында гы күзаллауларын баетуны дәвам итү; чыршы уенчыкла ры, аларның материалы, төсе, формасы белән таныштыру. Балаларда эстетик хисләр тәрбияләү. |
| январь | 1. | Ап-ак карлар ява. | Балаларны кар һәм аның үзлекләре (ак төстә, эри, йомшак, салкын, җиңел) белән таныштыру; тәрбияче сораула- рына җавап бирергә күнектерү; бала- ларның күзәтүчәнлеген үстерү; кышкы табигатькә соклану хисе, бергәләп уйнау теләге тәрбияләү. |
| | 2. | Алсу урамга җыена. | Балаларның кышкы киемнәр турында- гы белемнәренә төгәллек кертү, урамга чыкканда киенү эзлеклелеген ныгыту; фикерләвен, сүз байлыгын үстерү; башкаларга ярдәм итү теләге булдыру киемнәргә сак караш тәрбияләү. |
| | 3. | Ләйлә суыктан курыкмый (рәсем буенча). | Рәсемне карарга,рәсемдә ясалган пред- метларны танырга, исемнәрен дөрес әйтергә өйрәтү; предметларны, эш-хәрәкәтне, төсне белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүзлекне активлаш- тыру; рәсем эчтәлеге буенча сораулар- га җавап бирергә күнектерү;кабул итү сәләтен,игътибарны, хәтерне үстерү; сюжетлы рәсемнәр карарга теләк уяту. |
| | 4. | Күгәрченнәр, чыпчыклар- безнең нәни кошчыклар. | Мәйданчыкка килгән кошларны күзәтү, исемнәрен әйтү; гөр-гөр, кар-кар, чырык-чырыкаваз ияртемнәрен ачык итеп әйтергә күнектерү; том- шык, сикерә, гөрлиләр, җим чүпли- ләр, чыркылдыйлар, җитез, өлгерсүзләре хисабына сүзлекне баету; кошлар турында кайгырту, аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| февраль | 1. | Безнең әтиләр ( сюжетлы рәсемнәр карау). | Балаларны әтиләр һөнәренә кагылыш- лы сюжетлы кечкенә рәсемнәр карар-га,аларның эчтәлеген аңларга өйрәтү; эш гамәлләрне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын үстерү; төрле һөнәр кешеләренә, әти- ләре хезмәтенә кызыксыну уяту. |
| | 2. | Безнең апа. | Тәрбияче ярдәмчесе хезмәте белән бәйле эш- хәрәкәтләрне әөтергә өйрәтү ( савыт-саба юа, ашата, сөлгеләрне ал- маштыра, бүлмәне җыештыра һ.б.); сүзләрне активлаштыру, яңа сүзләр белән баету; балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү. |
| | 3. | Д.уен:" Алсу бәйрәмгә җыена". | Өс киемнәре,аларның төсе һәм материаллары белән таныштыруны дәвам итү,сүзлекне активлаштыру: ефәк,ак, чәчәклекебек яңа сүзләр кер- тү; балаларның игътибарын, фикерлә- вен,сорауларга кыска җөмләләр белән җавап бирү осталыгын үстерү; уенчыкларга сак караш тәрбияләү. |
| | 4. | КамАЗ машинасы. | Балаларны КамАЗ машинасының өлешләрен танырга исемен әйтергә өй- рәтү; уенның сүзләренә туры китереп хәрәкәтләр ясау осталыгы булдыру, балаларда йөк транспортына кызыксыну уяту; балаларның күзәтү- чәнлеген игътибарын, хәтерен, сөйлә- мен үстерү. |
| март | 1. | Безнең әниләр (сюжетлы рәсемнәр карау). | Балаларны әниләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү; төрле һөнәр кешеләренә һәм әниләр хезмәтенә карата кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү; балаларның кабул итү сәләтен, җавап бирү осталыгын үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2. | Матрешкалар. | Балаларны халык иҗат иткән уенчык- лар белән таныштыруны дәвам итү. Матрешкаларны ачарга һәм дөрес итеп җыярга өйрәтү, сүз байлыгын киңәйтү, активлаштыру; игътибарны, хәтерне, сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү; халык иҗатына кызыксыну, уенчыкларга карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | 3. | Матрешкалар. | Уенчыкның исемен дөрес әйтергә, тө- сендә һәм зурлыгында булган аерым- лыкларны күрә белергә күнектерү; зур, кечкенә, сарафан, яулык сүзләре хисабына сүзлекне активллаштыру,балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү, балаларда халык уенчыкларына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | 4. | Яз,яз килә... | Балаларга язгы күренешләр турында башлангыч белемнәр ( кар эри, там- чы тама, кояш җылыта, сулар җыела) бирү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру; балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын үстерү; табигатьтәге язгы күренешләр белән кызыксындыру. |
| апрель | 1. | Җәнлекләр урманда яшиләр. | Җәнлекләр турында балаларның белемнәрен киңәйтү һәм ныгыту,җән- лекләрне таный һәм исемнәрен атый белергә өйрәтү; балаларның диалогик сөйләмен активлаштыру, фикерләвен, мөстәкыйльлеген үстерү; җәнлекләр белән кызыксындыру. |
| | 2. | Сыерчыклар, карлыгачлар килде (рәсемнәр карау). | Балаларны үзләренә таныш кошларны рәсемнән танырга, исемнәрен әйтергә өйрәтү; игътибарны,күзәтүчәнлекне, тәрбияче белән аралашу осталыгын үстерү; кошлар белән табигать белән кызыксынуларына ирешү, кошларга карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучан- лык тәрбияләү. |
| | 3. | Песиле тал бөреләрен карау. | Балаларны песиле тал, аның өлешләре ( ботаклар,бөреләр) белән таныштыру, язгы күренешләр турында белемнәр формалаштыруны дәвам итү;песиле тал, ботак, бөре, йомшак, хуш исле-сүзләрен активлаштыру, балаларның кабул иү сәләтен, игътибарын,күзәтүчәнлеген, хәтерен үстерү; табигать белән кызыксыну,та- бигать матурлыгына соклану хисләре тәрбияләү. |
| | 4. | Тузганак чәчәген карау. | Балаларны үсемлекләр белән таныштыруны дәвам итү; тузга- нак чәчәген күрсәтү, аны танырга, исемен әйтергә, төзелеше буенча аера белергә өйрәтү; балаларның сенсор тою һәм кабул итү сәлә- тен , игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү; табигать белән турыдан- туры аралашудан шатлык хисләре булдыру,үсемлекләргә сакчыл караш тәрбияләү. |
| май | 1. | Йорт хайваннары. | Балаларның йорт хайваннары (сыер, ат, песи, эт) турындагы белемнәрен киңәйтү, хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен әйтергә күнектерү; суз- лекне баету, тәрбияченең сорауларына җавап бирү,мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләген үстерү; йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | 2. | Балалар тавык һәм чебиләр ашаталар.(рәсем буенча). | Балаларны рәсемне карарга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, тәр- бияче һәм иптәшләрен тыңларга өйрә- түне дәвам итү; сөйләмне томшык,тавык, чебиләр,табаксүзләре хисабына баету; игътибарны, хәтерне, образлы фикерләүне үстерү, йорт кош- ларына карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 3. | Ком һәм аның үзлекләре. | Балаларны комны тикшерергә, төсе буенча аның дымлылыгын билгеләргә өйрәтү;коры,дымлы, юеш,сибелүчән, әвәләүсүзләре хисабына балаларның сүз байлыгын киңәйтү, игътибарын, сенсор тою сәләтен үстерү;ком белән уйнарга кызыксындыру. |
| | 4. | Рәхмәт, җәй. | Балаларны яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне тәме буенча аерырга өйрәтүне дәвам итү; яшелчәләр, җил- ләк- җимешләр, агачлар турындагы белемнәрне киңәйтү; балаларның игъ - тибарын, кабул итү сәләтен үстерү; табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү. |

***Комплекслы – тематик план***

***ЭЛЕМЕНТАР МАТЕМАТИК ТӨШЕНЧӘЛӘР ФОРМАЛАШТЫРУ***

| Ай | № | Тема | Максат |
|---|---|---|---|
| сентябрь | 1. | Адаптация чоры. | Математик үсеш дәрәҗәсен күзәтү, тикшерү, әзерлекләрен формалаштыру; кыюлык тәрбияләү,шөгыльләргә катнашу, җавап бирү теләге уяту. |
| | 2. | Адаптация чоры. | Балаларны үз-үзләрен иркен тотарга, белгәнен кыенсынмый җавап бирергә булышу, кыюлык, тапкырлык тәрбияләү. |
| | 3. | Шар, куб. | Балаларны шар белән кубны аера һәм әйтә белүләрен ныгыту; төс,форма, зурлык төшенчәләрен кабул итәргә әзерләү. |
| | 4. | “Зур”, “кечкенә”. | “Зур”һәм “кечкенә” төшенчәләрен кулланып төрле зурлыктагы предмет-ларны үлчәү күнекмәләрен ныгыту; җылы, салкын, каты, йомшактөшенчәләрен кабул итәрлек шартлар булдыру. |
| октябрь | 1. | “Бер”, “күп”, “аз”. | “Бер”, “күп”, “аз” сүзләрен кулланып предметларның санын аерырга өйрәтүне ныгыту. |
| | 2. | Предметларны төркемләү. | Аерым предметларны төркемләү һәм төркемнән бер предметны аерып алу ысуллары белән таныштыру; “күп”, “бер”, “берәү дә юк” сүзләренең мәгънәләрен өйрәтү. |
| | 3. | Түгәрәк. | “Ничә?” соравына җавап бирү өчен “бер”, “күп”, “берәү дә юк” сүзләрен кулланырга өйрәтү. Түгәрәк белән таныштыру. Түгәрәкне тотып карау юлы белән дә тикшерү. |
| | 4. | Зур һәм кечкенә түгәрәк. | Түгәрәкләрне зурлыклары буенча чагыштыру;зур түгәрәк һәмкечкенә түгәрәк төшенчәләрен куллануТүгәрәкнең тотып карау юлы белән, хас билгеләрен әйтергә өйрәтү. |
| ноябрь | 1. | “Озын”, “кыска”. | Озынлыгы буенча ике предметны чагыштырырга өйрәтү, предметларны чагыштыруның төрле ысулларын өйрәтүне дәвам итү.Тотып карау юлы белән предметның билгеләрен әйтергә күнектерү. |
| | 2. | “Бер” , “күп”. | Билгеле урыннан бер яки күп предмет- ны таба белергә,”күпме?”-соравына җавап бирә белергә өйрәтү; озын(-рак), кыска(рак) сүзләрен куллану күнекмә-ләрен үстерү; күзаллауны үсиерү. |
| | 3. | Квадрат. | Квадрат белән түгәрәкне аерырга өйрәтү;тәрбияче соравы буенча рәсемдә бу фигураларны күрсәтергә өйрәтү; бер һәм күп предметларны аерып күр-сәтә алуга ирешү;зурлыгы ,формасы буенча предметларны аера алу күнек- мәләрен үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 4. | Квадрат һәм түгәрәк. | Билгеле төркем арасыннан бер һәм күп предметларны күрсәтү; квадрат белән түгәрәкне аера белергә өйрәтүне дәвам итү; форма, зурлык, төс турында белемнәрен үстерү. |
| декабрь | 1. | “Озын-кыска”, “озынрак-кыскарак”, “озынлыклары тигез”. | Ике предметны озынлыклары буенча чагыштыру күнекмәләрен үстерү. Озын-кыска, озынрак-кыскарак, тигезсүзләрен актив кулланылышка кертү. |
| | 2. | Түгәрәк һәм квадрат (ныгыту). | Түгәрәк һәм квадратларны дөрес аера һәм атый белү күнекмәләрен ныгыту; озынлыклары буенча ике предметны чагыштыру; тирә-яктагы бер һәм күп предметларны таба белү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | 3. | “Күбрәк”, “тигез”. | Төрле ике төркем предметларны берсе өстенә икенчесен куеп карау юлы белән чагыштырырга өйрәтү. Уң һәм сул кулларны аера һәм күрсәтә белү күнекмәләрен үстерү. |
| | 4. | “Ничә?”, “шулкадәр”. | Куеп карау юлы белән ике предметның озынлыгын чагыштырырга;күбрәк, тигез, шулкадәр,ничә сүзләрен сөйләмдә активлаштыру. |
| январь | 1. | “Киң-тар,киңрәк- тар- рак”. | Өстенә һәм кырыена куеп карау юлы белән киңлекләре буенча капма-каршы булган ике предметны чагыштырырга өйрәтү.Чагыштыру нәтиңәсенкиң-тар, киңрәк-таррак сүзләре белән билгеләү. |
| | 2. | Чагыштыру. | Киңлекләре буенча ике предметны чагыштыруны; ике тигез төркемдәге предметларны өстенә куеп карау юлы белән чагыштыруны камилләштерү; түгәрәк һәм квадратны аера, атый бе-лүләрен ныгыту. |
| | 3. | Өчпочмак. | Өчпочмак белән таныштыру, фигураны таный һәм атый белергә өйрәтү; ике предметны киңлекләре буенча чагыштыруны ныгыту;киңрәк-таррак, киңлеге буенча тигез сүзләрен чагыштыруларда кулланырга өйрәтү. |
| | 4. | Өчпочмак һәм квадрат | Квадрат белән чагыштырып карауга нигезләнеп өчпочмак белән танышты- руны дәвам итү. |
| февраль | 1. | “Алда-артта, өстә- аста, уңда-сулда”. | Геометрик фигураларны аера, таный, атый белүләрен камилләштерү; тирәлектә ориентлашырга, юнәлешләрне билгеләргә өйрәтү. |
| | 2. | “Биек- тәбәнәк, биегрәк-тәбәнәгрәк”. | Ике предметны биеклекләре буенча чагыштыру алымнары белән таныштыру.Ике тигез төркемдәге предметларны кырыена куеп карау юлы белән чагыштыру; тигез,шулай уксүзләрен куллануны камилләштерү. |
| | 3. | Чагыштыру. | Ике предметны биеклеге буенча чагыштыру күнекмәләрен үстерү. |
| | 4. | “Күбрәк,әзрәк,шулкадәр”. | Ике тигез булмаган предметлар төркемен чагыштыру; чагыштыруныкүбрәк, азрак, шулкадәр сүзләре кулланып билгеләү. |
| март | 1. | “Зуррак, кечерәк,ничә, шулкадәр”. | Тигез булмаган предметлы ике төркемне чагыштырырга өйрәтү; чагыштыру нәтиҗәләрензуррак, күбрәк, азрак, кимрәк, шулкадәр сүзләре белән билгеләү. |
| | 2. | Озынлык, киңлек, биеклек. | Ике предметны озынлыгы, киңлеге, биеклеге буенча чагыштыру;нәтиҗәне тиешле сүзләр белән белдерү. |
| | 3. | “Көн,төн”. | Тәүлек өлешләрен аера белергә, дөрес итеп атарга өйрәтүне дәвам итү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 4. | “Күп, бер” | Тавышны ишетеп санау күнекмәләрен үстерү; предметларны чагыштыру ысулларын ныгыту. |
| апрель | 1. | Санау. | Өч эчендә булган тавыш санын предметлар белән билгеләргә өйрәтү.Таныш геометрик фигураларны аера һәм атый белү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | 2. | Чагыштыру. | Ике предметны зурлыклары буенча чагыштыру күнекмәләрен үстерү; чагыштыру нәтиҗәләрензур,кечкенә сүзләре белән билгеләү. Предметларны зурлыгы, формасы, төсе буенча чагыштыру күнекмәләрен үстерү. |
| | 3. | “Бер , күп”. | Хәрәкәтләр санын аерырга һәм нәтиҗәне берһәм күп сүзләре белән билгеләргә өйрәтү.Предметларны төркемләү һәм төркемнән аерып алырга өйрәтүне дәвам итү;игъитбарны һәм фикерләүне үстерү. |
| | 4. | “Иртә , кич”. | Тәүлек өлешләрен аера һәм дөрес итеп атый белүне ныгыту; фикер-ләү сәләтен үстерү, предметларның урнашу тәртибен күрә белергә һәм тиешенчә үрнәк буенча урнашты- рырга өйрәтү. |
| май | 1. | “Өстендә, астында,эчендә”. | Тигез булган ике төркемне өстенә һәм кырыена куеп карау юлы белән чагыштыруны ныгыту.Предметның тирәлектә урнашу тәртибен өстендә, астында, эчендәсүзләре белән билгеләргә өйрәтү. |
| | 2. | Геометрик фигуралар. | Геометрик фигуралар ( түгәрәк, квадрат,өчпочмак, куб) турындагы белемнәрен камилләштерү.Игътибар, фикерләү, хәтер, иҗади күзал лауны үстерү. |
| | 3. | Кабатлау. | Балаларның ишетеп һәм тоемлап сиземләү тәҗрибәсен баету. |
| | 4. | Ориентлашу. | Гәүдә өлешләрендә ориентлашуны камилләштерү (уң кул, сул кул, уң аяк, сул аяк); үзләреннән кайсы юнәлештә урнашуына карап, тирә-яктагы әйберләрнең торышын бил геләү күнекмәләрен үстерү; тәүлектә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү (көн-төн, иртә-кич). |

### 2.3. «СӨЙЛӘМ ҮСЕШЕ»

***СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ***

***Аңлатма язуы***

Балаларның тирә- юнь турындагы белемнәре арту нәтиҗәсендә аларның сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру. Әйберләрнең өлеш-кисәкләрен атарга, аларның формаларын һәм төсләрен, нәрсәдән ясалуын әйтә белергә өйрәтү.

Гомумиләштерүче сүзләрнең мәгънәсен аңлый белергә өйрәтү.

Тирә- юньдәге әйберләрнең исемнәрен куллануны активлаштыру. Сөйләшкәндә таныш әйберләрнең исемен, сыйфатын, хәрәкәт урынын аңла- та торган сүзләрне куллана белү күнекмәләре бирү.

Балаларның артикуляция аппаратын камилләштерү һәм фонематик ишетү сәләтен үстерү юнәлешендә эзлекле эш алып бару.

Авазларны, сүзләрне һәм гади җөмләләрне ашыкмыйча, ачык һәм аңлаешлы итеп әйтергә өйрәтү.

Балаларның җөмләләрне дөрес итеп төзи белү күнекмәләрен арттыру.

Хайваннарның, кош-кортларның һәм аларның балаларының атамаларын берлек санда, күплек кушымчалары ялгап дөрес итеп әйтергә өйрәтү.

Зурлар һәм иптәшләре белән иркен аралашырга; төрле эшчәнлекләрдә диалогик, монологик сөйләм формаларын кулланырга өйрәтү.

Рәсемнәр, иллюстрацияләр, уенчыклар буенча тәрбияче биргән сорауларга җавап кайтарырга өйрәтү.

Балаларны хикәя төзеп сөйли белергә хәзерләү: күргән уенчыклар яки рә- семнәр турында 3-4 җөмләдән торган хикәяләрне тәрбияче артыннан кабатлау. Таныш әкиятләрнең кайбер өлешләрен рольләргә бүлеп сөйләргә өйрәтү.

***Комплекслы – тематик план***

***Әдәби сөйләмне үстерү.***

| Айлар | 1 нче атна | 2 нче атна | 3 нче атна | 4 нче атна |
|---|---|---|---|---|
| **Сентябрь** | **Тема: "Коящ,чык!"**<br>**Бурычлар:**<br>**1)**җәй турында күзаллауларга нигез салу,тәүлек өлешләрен дөрес әйтергә күнектерү;<br>**2)**балаларның сөйләмен,игътибарын,ишетү хәтерен;күз алдына китерә,хыяллана белүләрен;вак маториканы,рәсем ясау күнекмәсен,иҗади сәләтләрен үстерү;<br>**3)**балаларда табигать белән кызыксыну тәрбияләү. | **Тема: "Ә"авазы**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** "ә" сузык авазын дөрес итеп, кыска һәм озын итеп әйтергә күнектерү.<br>**2)** "Ә"авазын аерым сүзләрдә һәм җөмләләрдә әйтүне ныгыту;сорауларга җавап бирергә теләк уяту;<br>**3)** сюжетны чагылдыра торган уеннарда катнашу теләге тәрбияләү. | **Тема: "Йомшаккай әзерләгән сюрприз"**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** агачтан ясалган уенчыкларны карау барышында агач материалы,аның үзлекләре (каты,нык)белән таныштыру;тәрбияче сорауларына җавап бирергә өйрәтү;<br>**2)** предметның төсен,формасын,зурлыгын билгели белергә өйрәтү,анализаторлар эшчәнлеген,сүзлек байлыгын,хәтерләрен,игътиба рын үстерү;<br>**3)**уенчыкларга карата сакчыл каращ,уеннан соң уенчыкларны урыннарына кую гадәте тәрбияләү.<br>Әдәбият: | **Тема: "Манара"**<br>**Бурычлар:**<br>**1)**балаларны төрле зурлыктагы һәм төрле төстәге төзү материалы-шакмаклар белән таныштыру, үрнәк буенча манара корылмасы төзергә өйрәтү.<br>**2)**предметның төсен,формасын,зурлыгын атый белүләренә ирешү;<br>**3)** бергә шөгыльләнү теләге уяту;балалар бакчасына карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| **Октябрь** | **Тема: "Бакчада алмалар өлгерде"**<br>**Бурычлар:** | **Тема:"Алтын көз"**<br>**Бурычлар:** | **Тема:"Куян үстергән кишер һәм помидор!"**<br>**Бурычлар:** | **Тема:"Сары,кызыл яфраклар"**<br>**Бурычлар:** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **1)**балаларның табигатьтәге көзге үзгәрнешләр,җиләк-җимешләр (алма,анның билгеләре) турында күзаллауларын баету нигезендә сүзлек запасын киәйтү һәм активлаштыру;<br>**2)**балаларның игътибарын,хәтерен,сенсорик күнекмәләрен,артикуляция аппаратын үстерү;<br>**3)**күмәк эшләүгә тарту,сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләү. | **1)** тиңдәш кисәкләрдән торган җөмләләр төзергә,аерым предметлардан төркем төзергә,аерым предметлардан төркем төзергә,характерлы билгеләре буенча предметны төркемнән аерырга өйрәтүне дәвам итү;<br>**2)** балаларның игътибарын,зиһенгә алуларын үстерү; тәрбияче соравына аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү;<br>**3)** табигатькә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. | **1)** балаларга табигатьтәге көзге үзгәрешләр,көзге уңыш турында мәгълүмат бирү,яшелчәләр турындагы белемнәрен ныгыту;<br>**2)** балаларның яшелчәләрне тышкы күренеше,тәме,формасы буенча аера белүләренә ирешү;сенсорик күнекмәләрен үстерү;<br>**3)** балаларда сорауларга җавап бирү теләге уяту;табигатькә уңай караш тәрбияләү. | **1)** балаларны көз,кыш ел фасылларының характерлы билгеләре белән таныштыру;көзге яфраклар турындагы белемнәрен киңәйтү;<br>**2)** балаларның игътибарын,аңга алуларын,хәтерен,бәйләнешле сөйләмен үстерү;<br>**3)** балаларда чиста пөхтә эшдәү теләге тәрбияләү. |
| **Ноябрь** | **Тема:**<br>**"Безнең гаилә"**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларның гаилә һәм гаилә әгъзалары турындагы белемнәрен баетуны дәвам итү;исемнәрне сана, тартым белән төрләндерүгә күнектерү;<br>**2)**балаларның игътибарын,хәтерен,аңга алуларын үстерү;<br>**3)** Олылар белән ирекле аралашу күнекмәләре; гаиләгә һәм гаилә әгъзаларына карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | **Тема:**<br>**"Уенчык песи баласы турында хикәяләү"**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларның гаилә турындагы күзаллауларын киңәйтү;уенчыкны карауга балаларны җәлеп итү;уенчыкны сорауларга җавап бирү юлы белән тасвирларга өйрәтүне дәвам итү;<br>**2)** балаларның игътибарын,аңга алуларын,хәтерен,бәйләнешле сөйләмен үстерү<br>**3)** тәрбияче һәм иптәшләре белән аралашу теләге уяту;йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | **Тема:**<br>**"Кунак каршылыйбыз"**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** савыт-сабаның аерым предметлары,аларның кулланылышы турындагы белемнәренә төгәллек кертү;әңгәмәгә тарту;<br>**2)** балаларның игътибарын,аңга алуларын,хәтерен,бәйләнешле сөйләмен үстерү.үз исемен дөрес итеп әйтә белергә өйрәтү;<br>**3)** балаларда сөйләм этикетына нигез салу;өлкәннәргә булышу теләге уяту;савыт-сабаларга сакчыл караш тәрбияләүю | **Тема:**<br>**"Алсуның яңа өе"**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларны йорт җиһазлары белән таныштыру,билгеләнешләре буенча гомумиләштерергә өйрәтү;<br>**2)** җиһаз предметларының атамасын һәм билгеләнешен,аларның нинди материалдан эшләнгәнен ачыклауларына ирешү;<br>**3)** йорт җиһазларына карата сакчыл караш тәрбияләү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Декабрь** | **Тема:“Мин- Түбән Кама шина оныгы”**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларны туган шәһәр,аның исеме (Түбән Кама),аның заводында ясала торган шиналар белән таныштыру,аларның кулланылышын аңлату;<br>**2)** аңга алуларын,диалогиг сөйләмнәрен үстерү;<br>**3)** туган шәһәр,завод эшчеләренең хезмәте белән горурлану хисе тәрбияләү. | **Тема:“Төлке бездә кунакта”**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** сөйләмдә бәйлек сүзләрне (эчендә,өстә,артында) кулланырга, “кайда?,кая?” сорауларына җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү;<br>**2)** игътибарны,тәрбияченең күрсәтмәләре буенча эшләү күнекмәләрен үстерү;<br>**3)** җәнлекләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | **Тема:“Тылсымлы шкатулка”**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларны Яңа ел бәйрәменә әзерлеккә тарту,чыршы уенчыкларының төрләре белән таныштыру,аларны күзәтергә теләк тәрбияләү.<br>**2)** балаларны чыршы уенчыкларының төсен,формасын,зурлыгын кулланылышын билгеләргә өйрәтү;<br>**3)** чыршы уенчыкларына сак караш тәрбияләү,балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф,шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру. | **Тема:**<br>**“Алсуны урамга киендерәбез”**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** кышкы киемнең билгеләнешен, төсен,аерым детальләрен,материалын атап, анны сүрәтләргә өйрәтүне дәвам итү.<br>**2)** тукыма,мех, йомшак,җылы,шома, ак,яшел,зәңгәр сүзләре хисабына сүзлекләрен активлаштыру;<br>**3)** киемнәргә карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| **Январь** | | | **Тема:**<br>**“Куян белән тиенне чыршы бәйрәменә чакырабыз”**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларның кышкы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре,кыргый җәнлекләр турындагы күзаллауларын киңәйтү;<br>**2)** балаларның игътибарын,хәтерен үстерү,танып белү активлыкларын формалаштыру;<br>**3)** балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф,шатлык | **Тема:**<br>**“Кар ява”**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларның кыш турында күзаллауларын киңәйтү;кар,аның билгеләре белән таныштыруны дәвам итү;<br>**2)** балаларның игътибарын,диалогик сөйләмен,рәсем ясауга кызыксынуларын,пространств ода ориентлашуларын,сөйләм сулышын үстерү;<br>**3)** башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | хисләре булдыруга шартлар тудыру;җәнлекләргә карата кайгыртучанлык хисе тәрбияләү. | Әдәбият: |
| **Февраль** | **Тема:**<br>**“Чана шуабыз” рәсемен карау**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларны рәсем карарга,аның эчтәлеген аңларга,эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү;<br>**2)** диалогик сөйләмнәрен;күзәтүчәнлекләрен,күрсәтмә образлы фикерләүләрен үстерү;<br>**3)** кышның матурлыгын күрә белергә өйрәтү. | **Тема:**<br>**“Җимлек янында”**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** кышлаучы кошларны күзәтүне оештыру;аларның тышкы кыяфәте буенча танырга өйрәтүне дәвам итү;<br>**2)** аваз ияртемнәрен әйтүдә күнктерү; сүзлек запасын баету,күзәтүчәнлекләрен үстерү;<br>**3)** кошларга карата сак карашаларны турында кайгыртучанлык,кышын аларны тукландыру теләге тәрбияләү | **Тема:**<br>**“Очучылар”**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларны самолетның өлешләрен,зурлыгын,формасын билгеләргә һәм атарга өйрәтү;<br>**2)** балаларның нинди? кайда? кая? нәрсә? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирүләренә ирешү;<br>**3)** очучы һөнәренә хөрмәт,патриотик хисләр тәрбияләү. | **Тема:**<br>**“Ватанны саклаучылар көне”**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларны Ватанны саклаучылар көне белән таныштыру;<br>**2)** балаларның игътибарын, аңга алуларын,диалогик,монологик сөйләмнәрен үстерү;<br>**3)** балаларда Туган илгә мәхәббәт,малайларда көчле,кыю булырга омтылыш тәрбияләү. |
| **Март** | **Тема:“Кояш гомере телим мин,әнием, сиңа!”**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларның әниләр бәйрәме турындагы белемнәрен киәйтү;<br>**2)** балаларның игътибарын,аңга алуларын,диалогиг сөйләмнәрен үстерү;<br>**3)** балаларда әниләргә мәхәббәт һәм аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. | **Тема:“Минем әнием”**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** әниләр турында әңгәмәдә катнашырга,әниләрнең исемен дөрес әйтә белергә өйрәтү;әзер формалардан бизәк төзеп,кәгазь битендә ябыштырырга өйрәтүне дәвам итү;<br>**2)** балаларның игътибарын,аңга алуларын,хәтерен,бәйләнешле сөйләмен үстерү;<br>**3)** балалрда пөхтәлек,әниләргә карата жылы | **Тема:“Тере һәм уенчык кошларны карау”**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** тере һәм уенчык кошны чагыштырып,уенчык кош-дымка уенчыгы белән таныштыру,уенчык кошның нинди материалдан ясалган булуын ачыклау;төсләрне,дымка бизәге элементларын ныгыту;<br>**2)** балаларның игътибарын,зиһенгә алуларын үстерү; тәрбияче соравына | **Тема:“Теремкәй”рус халык әкиятен сөйләү**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга,сюжетның эзлеклелеген күзәтә белергә өйрәтү;<br>**2)** Тычкан-Чыелдык,бака-Бакылдык,куян-Куркаккай,һ.б.сүзтезмәләре хисабына балаларның сүзлеген баету; |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | мөнәсәбәт,хөрмәт,мәхәббәт тәрбияләү. | аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү;<br>**3)** кошлар белән кызыксыну,аларга карата сак караш тәрбияләү. | **3)** халык иҗатына кызыксыну тәрбияләү. |
| **Апрель** | **Тема:"Урамда яз"**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларны язгы күренешләр белән таныштыруны дәвам итү;<br>**2)**балалрның күзәтүчәнлеген,игътибарын,к үзаллавын үстерү;<br>**3)** язгы күренешләр белән кызыксынуларын үстерү. | **Тема:"Бозау,колын,бәрән турында сөйлибез"**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** язгы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре турында күзаллауны киңәйтү,тәрбияче белән бергә уенчык турында кечкенә хикәя (2-3 җөмлә) төзергә өйрәтү;<br>**2)** балаларның аңга алуларын,монологик сөйләмен үстерү;<br>**3)** балаларда хайваннар тормышы белән кызыксыну тәрбияләү. | **Тема:"Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре"рәсемен карау**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларны тәрбияче ярдәме белән рәсемнең эчтәлеген аңларга,аның турында сөйләргә өйрәтү,йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү.<br>**2)** балаларның аңга алуларын,игътибарын,диалог ик сөйләмен,дуслык турында күзаллауларын үстерү;<br>**3)** тәрбияче сөйләгәнне тыңлый белергә өйрәтү;хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | **Тема:"Агачлар,куаклар"**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларның агачлар,куаклар турындагы белемнәрен киңәйтү;аларның үзенчәлекле билгеләрен камилләштерү;<br>**2)** балалрның күзәтүчәнлеген,игътибарын,к үзаллавын үстерү;<br>**3)** табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. |
| **Май** | **Тема:"Саф һавада"**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларның чәчәкләр,бөҗәкләр турындагы белемнәрен системалаштыру;<br>**2)** балаларның игътибарын,диалогик сөйләмен,уңай хис-кичерешләрен,аңга алуларын үстерү; | **Тема:"Тузганак чәчәген карау"**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** баларны туган як үсемлекләре (тузганак)белән таныштыруны дәвам итү;<br>**2)** үсемлекне карау барышында әңгәмәгә тарту;хәтерне,күзәтүчәнлекне үстерү; | **Тема:"Автобуста сәяхәт"**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** балаларның аваз ияртемнәрен әйтә белүләренә ирешү,йорт хайваннары төшенчәсен ныгыту,йорт хайваннары,кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>**2)** кошларның,хайваннарның хәрәкәтен белдерә торган фигыльләр,иркәләп,яратып | **Тема:"Мин җәйне яратам"**<br>**Бурычлар:**<br>**1)** табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү;<br>**2)** балаларның игътибарын,диалогик сөйләмен,уңай хис-кичерешләрен,аңга алуларын үстерү;<br>**3)** табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **3)** табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. | **3)** үсемлекләр белән кызыксыну,эстетик хисләр тәрбияләү. | әйтелә торган сүзләр хисабына сүзлекләрен активлаштыру;<br>**3)** тере һәм тере булмаган табигать беләнкызыксынутәрбияләү. | |

**Сөйләм үстерү үсеш өлкәсе.**

**"Матур әдәбият уку"**.

«Матур әдәбият уку» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Әдәби әсәрләрнең төрле жанр һәм тематикасын - халык әкияте, татар язучылары һәм шагыйрьләренең хикәя, шигырьләрен, шигъри фольклорның кече формаларын тыңлау, аларның эчтәлегенә хисләрен белдерү сәләтен үстерү.

Әкият геройлары һәм аларның характерлары, чынбарлыкта булган хәлләр, балалар һәм өлкәннәр эшләгән эшләр турындагы күзаллаулар ярдәмендә баланың эчке дөньясын баету, укыганны аңлар өчен сораулар бирү һәм фикер алышу.

Тәрбияче ярдәмендә татар әкиятләреннән өзекләрне сәхнәләштерергә өйрәтү.

Укыган әсәрдән аеруча кызыклы, сәнгатьле өзекләрне кабатлаганда, балаларга сүзләрне һәм катлаулы булмаган фразаларны әйтеп бетерергә мөмкинлек бирү.

Кечкенә күләмле шигырьләрне, шигъри фольклорның кече формаларын яттан сөйләүләрен хуплау.

Уен һәм сәнгать эшчәнлекләрен, конструкцияләү һ. б. ны әдәби образлар белән баету.

***Комплекслы – тематик план***

**"Матур әдәбият уку"**.

| **Ай исеме** | **Оештыру эшчәнлеге** |
|---|---|
| Сентябрь | Ә. ЕРИКӘЙНЕҢ «КӨЗ» ШИГЫРЕН ЯТТАН ӨЙРӘНҮ.<br>«АЮ БЕЛӘН БАБАЙ» ӘКИЯТЕН УКУ |
| Октябрь | «АЮ БЕЛӘН БАБАЙ» ӘКИЯТЕН УКУ |
| Ноябрь | «БАШ БАРМАК...» ШИГЪРИ ӘСӘРЕН УКУ УЕНЧЫК ПЕСИ БАЛАСЫ ТУРЫНДА ХИКӘЯЛӘҮ<br>Ә.БИКЧӘНТӘЕВАНЫҢ «БӘТИЛӘР» ШИГЫРЕН УКУ. |
| Декабрь | «КЕМ НӘРСӘ ЯРАТА?» ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЕН УКУ.<br>«КЕМ НӘРСӘ ЯРАТА?» ТАТАР ХАЛЫКӘКИЯТЕН СӨЙЛӘҮ |
| Гыйнвар | Һ.ТАКТАШНЫҢ «ЛӘЙЛӘ» ШИГЫРЕН УКУ<br>Ә. БИКЧӘНТӘЕВАНЫҢ «САЛКЫН САФ ҺАВА» ШИГЫРЕН ЯТЛАУ |

| | |
|---|---|
| Февраль | ОЧУЧЫЛАР<br>З. ТУФАЙЛОВАНЫҢ « ШОФЕР БУЛАМ» ДИГӘН ШИГЫРЕНУКУ. |
| Март | КОЯШ ГОМЕРЕ ТЕЛИМ МИН, ӘНИЕМ,СИҢА!<br>З. ТУФАЙЛОВНЫҢ «ӘНИ СҮЗЕ» ШИГЫРЕН ЯТЛАУ<br>Л. ТОЛСТОЙНЫҢ «ӨЧ АЮ» ӘКИЯТЕН УКУ |
| Апрель | Б. РӘХМӘТНЕҢ «ЯЗ» ШИГЫРЕН ЯТЛАУ<br>БОЗАУ, КОЛЫН, БӘРӘН ТУРЫНДА СӨЙЛИБЕЗ<br>«ТЕРЕМКӘЙ» РУС ХАЛЫК ӘКИЯТЕН СӨЙЛӘҮ |
| Май | «ТӨЛКЕ, КУЯН ҺӘМ ӘТӘЧ» ӘКИЯТЕН СӘХНӘЛӘШТЕРҮ<br>Х. ВАХИТНЫҢ «УҢГАН СЫЕРЧЫК» ШИГЫРЕН УКУ |

**2.4. «ИЖАДИ - ЭСТЕТИК ҮСЕШ»**

***СӘНГАТЬ ИЖАДЫ***

***Аңлатма язуы***

«Ижади сәнгать» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда әйләнә-тирәдәге матурлыкка кызыксыну уятуны ҺӘМ үз- үзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә ҺӘМ белем бирү бурычларын билгели.

Балаларда сынлы сәнгать шөгыльләренә кызыксыну тәрбияләү. Рәсем, әвәләү, кисеп ябыштыру шөгыльләрендә әйләнә-тирәдәге гади генә предметларны һәм күренешләрне образлы итеп сурәтләргә, рәсемнәрне кәгазь битенә урнаштырырга өйрәтү.Кисеп ябыштыруның иң гади күнекмәләрен бирү.

Балаларны предметларның формасы, зурлыгы, төзелеше, төсе белән таныштыруны дәвам итү.

Рәсемдә, иллюстрацияләрдә, халык уенчыкларында төсләрнең матурлы- гын, ачыклыгын күрә белергә өйрәтү.

Кулга каләм, пумала тотарга өйрәтүне дәвам итү. Төсләрне белүләрен ныгыту. Балаларны яңа төсмерләр ( алсу, сыек зәңгәр,соры) белән таныштыру. Предметка туры килгән төсне сайлап алырга өйрәтү.

Штрих,буяуларны салмак төшерергә, әйләнә-тирә чынбарлыктагы күре- нешләрне һәм предметларны сурәтләргә өйрәтү.

Төрле юнәлештәге туры, авыш, озын, кыска сызыклар үткәрергә, аларны кисештерергә, түгәрәк формалы предметларны һәм күренешләрне сурәтләргә,формасы турыпочмаклы предметларны, түгәрәк һәм турыпочмаклы фораларны бергә катнаштырып әйләнә-тирә чынбарлыктагы предмет һәм күренешләрне сурәтләргә өйрәтү.

Әвәләү белән кызыксыну тәрбияләү. Балчыкның үзлекләре белән таныштыруны дәвам итү. Балаларны катлаулы булмаган әйберләр:шар, каләм,табак, тәлинкә, клиндер ясарга өйрәтү.

Бер үк төрле һәм төрле формадагы берничә өлештән торган гадирәк предметларны бер өлешен икенчесенә тыгыз итеп кысып ябыштыру юлы белән әвәләргә өйрәтү.

Балаларда ябыштыру шөгыленә кызыксыну тәрбияләү.Тәрбияче әзерләп биргән 2-3 кисәктән торган предметларның сурәтләрен кәгазь битенә тезеп чыгарга һәм ябыштырырга өйрәтү. Җилем белән эшләү күнекмәләрен үстерү. Геометрик элементлардан буй сызыкта, квадратта, турыпочмаклыкта, түгәрәктә төсе, формасы, зурлыгы буенча чиратлаштырып бизәк төзү күнекмәләре бирү.

***Комплекслы – тематик план***

**Рәсем ясау. Әвәләү. Кисеп ябыштыру**

| айлар | Рәсем ясау | Әвәләү | Кисеп ябыштыру |
|---|---|---|---|
| **Сентябрь** | | **1 атна** | |
| | **Тема: «Карандаш һәм кәгазь белән танышу»**<br>**Максат:**Карандашны дөрес тотарга, каты кысып тотмыйча, басмыйча кәгазьдә карандаш белән рәсемләргә өйрәтү. Балаларның игътибарын карандаш калдырган эзләргә юнәлтү, бармаклар белән сызыклардан йөртү. Штрих белән предметлар арасындагы охшашлыкны күрергә өйрәтү.Рәсемләүгә теләк үстерү. | **Тема: «Балчык, пластилин белән танышу»**<br>**Максат:**Балчык йомшак, аңардан нәрсә телисең, шуны әвәләп булуын балаларга аңлату.Зур кисәктән кечкенә кисәкләр чеметеп алып булуын төшендерү.Балчыкны һәм әвәләнгән әйберне тактага гына куярга кирәклеген, пөхтә эшләргә өйрәтү.Әвәләүгә теләк үстерү. | |
| | | **2 атна** | |
| | **Тема: «Яңгыр ява»**<br>**Максат:** Балаларны әйләнә- тирә тормыштан алган тойгыларны рәсемләүдә күрсәтергә өйрәтү.Карандашны дөрес тоту, сызык, штрихларны кыска итеп рәсемләү осталыкларын ныгыту.Рәсемләүгә теләк үстерү. | | **Тема: «Зур һәм кечкенә туплар»**<br>**Максат:**Балаларны түгәрәк формадагы зур һәм кечкенә предметларны сайларга өйрәтү. Түгәрәк формадагы предметларның зурлыгы буенча аерымлыклары турында күзаллауны ныгыту. Пөхтә ябыштырырга өйрәтү. |
| | | **3 атна** | |
| | **Тема: «Шарларга төсле җепләр бәйлибез»**<br>**Максат:** Сызык сызганда карандашны дөрес тотып, кәгазьдән аермыйча өстән аска таба рәсемләргә өйрәтү. Эстетик кабул итүне үстерү.Сызыкларда предмет образын күрергә өйрәтү. | **Тема: «Таяклар»**<br>**Максат:**Балаларны балчыкны чеметеп алып ике уч арасында туры хәрәкәтләр белән тәгәрәтергә өйрәтү. Пөхтә эшләргә, әвәләгән әйберләрне тактага гына куярга өйрәтү. | |
| | | **4 атна** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Тема: «Матур баскыч»**<br>**Максат:** Балаларны өстән аска таба , туры итеп, туктамыйча сызык сызарга өйрәтү. Пумаланың барлык төкләрен дә буяуга манып алып, артык буяуны стакан кырыена сыгып җиңел хәрәкәтләр белән буярга өйрәтү. Суда пумаланы юып, чүпрәктә корыту һәм башка төс кулланырга өйрәтү.Төсләр белән таныштыруны дәвам итү. Эстетик үзләштерүне үстерү. | | **Тема: «Шарлар юлда тәгәриләр»**<br>**Максат:** Балаларны түгәрәк формалы предметлар белән таныштыру.Бармаклар белән түгәрәк тирәли йөртеп аның түгәрәк икәнлеген әйтергә теләк тудыру.Ябыштыру алымнарына өйрәтү.Иҗадилыкны үстерү. |
| **Октябрь** | | **1 атна** | |
| | **Тема: «Яфраклардан төсле келәм»**<br>**Максат:** Образлы күзаллауны, эстетик үзләштерүне үстерү. Балаларны пумаланы дөрес тотарга, пумаланың барлык төкләрен дә буяуга манып алып, артык буяуны стакан кырыена сыгып рәсемләргә өйрәтү.Яфракларны пумала төкләренең очы белән генә рәсемләргә өйрәтү. | **Тема: «Йомры икмәк»**<br>**Максат:** Балаларда әвәләүдә әкияти персонажларны әвәләргә теләк уяту.Түгәрәк формалы предметларны ике уч арасында тәгәрәтеп әвәләү осталыкларын ныгыту.Балчык белән пөхтә эшләү осталыгын ныгыту. Кискеч белән кайбер детальләрен ( күзләр, авыз)рәсемләргә өйрәтү. | |
| | | **2 атна** | |
| | **Тема: «Төсле йомгаклар»**<br>**Максат:** Балаларны өзлексез түгәрәк хәрәкәтләр белән, карандашны дөрес тотып, кәгазьдән аермыйча рәсемләргә өйрәтү.Рәсемләү процессында төрле төсле карандашлар кулланырга өйрәтү.Балаларның игътибарын төрле төсле сүрәтләрнең матурлыгына юнәлтү. | | **Тема: «Тәлинкәдә зур һәм кечкенә алмалар»**<br>**Максат:** Балаларны түгәрәк формалы предметларны ябыштырырга өйрәтү.Предметларның зурлыгы буенча аерымлыклары булуына күзаллауны ныгыту. Дөрес ябыштыру алымнарын ныгыту. |
| | | **3 атна** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Тема: «Өрел, өрел куык...»** **Максат:** Балаларны хәрәкәтле уен образын рәсемләргә өйрәтү. Түгәрәк формалы предметларны төрле зурлыкта рәсемләү осталыкларын ныгыту. Пумаланы дөрес тотып, буяу белән рәсемләү осталыкларын формалаштыру.Төсләрне белүләрен ныгыту. Күзаллауны, образлы күзаллауны үстерү. | **Тема: «Яраткан эт баласына бүләк»** **Максат:**Образлы үзләштерүне һәм образлы күзаллауны формалаштыру, иҗадилыкны һәм күзаллауны үстерү.Әвәләүдә алдан өйрәнгән алымнарны һәм осталыкларны кулланырга өйрәтү.Хайваннарга карата мәрхәмәтлелек сыйфаты тәрбияләү һәм аларга нинди дә булса яхшылык эшләү теләге уяту. | |
| | | **4 атна** | |
| | **Тема: «Уйлау буенча рәсемләү»** **Максат:** Балаларны рәсемнең эчтәлеген мөстәкыйль уйларга өйрәтү.Алдан өйрәнгән буяу белән рәсемләү алымннарын ныгыту.Рәсемнәрне карау һәм аларга карап шатлану хисе булдыруга теләк тәрбияләү. Иҗадилык, төсле үзләштерүне үстерү. | | **Тема: «Тәлинкәдә җиләк һәм алмалар ята»** **Максат:** Балаларны предметларның формасы турындагы белемнәрен ныгыту.Предметларны зурлыгы буенча аерырга өйрәтү. Җилем белән пөхтә эш итү,салфетка куллануда күнектерү.Кәгазьдә сүрәтләрне иркен урнаштырырга өйрәтү. |
| **Ноябрь** | | **1 атна** | |
| | **Тема: «Нәрсә дә булса матур итеп яса»** **Максат:** Рәсемләүгә теләк уяту.Уйлаган уйны рәсемдә күрсәтә белү аның эчтәлеген мөстәкыйль уйлау осталыгын үстерү.Карандашлар белән рәсемләүне күнектерү.Үзләренең һәм иптәшләренең рәсеменә карап шатланырга, ясалган предметларны. күренешләрне атарга өйрәтү. Иҗадилыкны үстерү, мөстәкыйльлек тәрбияләү. | **Тема: «Прәннекләр»** **Максат:**Балаларны шарлар әвәләүдә ныгыту. Учлар белән кысып, шомартырга өйрәтү. Башкаларга нәрсә дә булса ясау теләге үстерү. | |
| | | **2 атна** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Тема: «Матур һава шарлары»**<br>**Максат:** Балаларны түгәрәк формалы предметлар рәсемләргә өйрәтү. Карандашны дөрес тотарга өйрәтү. Рәсемләү процессында төрле төсләрне куллануны ныгыту. Рәсемләүгә кызыксыну үстерү. | | **Тема: «Өйләрдә төрле төсле утлар»**<br>**Максат:** Балаларны түгәрәк формалы сүрәтләрне ябыштырырга өйрәтү.Сүрәтләрнең формаларын атап әйтүләренә ирешү.Төрле төстәге түгәрәкләрне чиратлаштырып ябыштырырга өйрәтү. Пөхтә ябыштыруда күнектерү.Төсләрне белүләрен ныгыту. |
| | | **3 атна** | |
| | **Тема: «Төрле төстәге тәгәрмәчләр»**<br>**Максат:** Балаларны пумаланы кәгазьдән аермыйча өзлексез сызып түгәрәк формалы предметлар рәсемләргә өйрәтү. Пумаланы юу, чүпрәктә корыту осталыкларын ныгыту. Төсләрне үзләштерүне үстерү. Төсләрне белүләрен ныгыту. | **Тема: «Крендельләр»**<br>**Максат:**Балчыкны ике уч арасына алып туры хәрәкәтләр белән тәгәрәтү алымын ныгыту.Барлыкка килгән фигураның ике очыннан тотып тоташтырырга өйрәтү. Балаларда эшләрен карау, аларның охшаш һәм аермалы якларын табып әйтә белү осталыкларын формалаштыру. | |
| | | **4 атна** | |
| | **Тема: «Түгәрәк формалы нәрсә дә булса рәсемлә»**<br>**Максат:** Түгәрәк формалы предметлар рәсемләүдә күнектерү. Буяу белән эш итү, пумаланы дөрес тоту осталыкларын ныгыту. Башка төрле төскә буяганда пумаланы юу һәм эш беткәч тә пумаланы юып куярга өйрәтү. Иҗадилык, мөстәкыйльлек үстерү. | | **Тема: «Шарлар һәм кубиклар»**<br>**Максат:** Балалар өчен яңа форма-квадрат белән таныштыру. Квадрат белән түгәрәкнең аермалы якларын атап чагыштырырга өйрәтү. Бу фигураларны чиратлаштырып ябыштырырга өйрәтү. Дөрес итеп ябыштыру алымнарын ныгыту. Төсләрне белүләрен ачыклау. |
| **Декабрь** | | **1 атна** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Тема: «Зур һәм кечкенә кар йомарламнары»**<br>**Максат:** Түгәрәк формалы предметларны рәсемләү осталыкларын ныгыту. Буяу белән дөрес итеп буяу алымнарын өйрәтү. Кәгазь битендәге бушлыкны тутыру өчен, сүрәтләрне кабатлап рәсемләргә өйрәтү. | **Тема: «Шалтыравыклар»**<br>**Максат:**Балаларны ике өлештән торган предмет әвәләргә өйрәтү. (түгәрәк һәм таякчык, әлеге өлешләрне бер-берсенә нык итеп чеметеп ябыштыру, беркетү) Ике уч арасында балчыкны туры һәм түгәрәк хәрәкәтләр ясап тәгәрәтүдә күнектерү. | |
| | | **2 атна** | |
| | **Тема: «Чыршыкай»**<br>**Максат:** Балаларны чыршы образы рәсемләргә өйрәтү. ( сызыклардан гына торган предмет) Буяу һәм пумала белән кулланырга өйрәтүне дәвам итү. | | **Тема: «Пирамида»**<br>**Максат:**Балаларны кисеп ябыштыруда уенчык образын бирергә өйрәтү. (уенчыкның детальләрен зурдан кечерәя бару тәртибендә урнаштыру, берничә өлештән торган уенчыкны сүрәтләү)Төсләрне белүләрен ныгыту. |
| | | **3 атна** | |
| | **Тема: «Безнең кишәрлектәге агачлар»**<br>**Максат:** Балаларны агач образы рәсемләргә өйрәтү. (Туры, вертикаль, авыш сызыклардан торган предметны зур итеп тулы биткә урнаштыру) Буяу белән рәсемләргә өйрәтүне дәвам итү. | **Тема: «Башня»**<br>**Максат:**Балаларны ике уч арасында балчык кисәген түгәрәк хәрәкәтләр белән тәгәрәтергә өйрәтүне дәвам итү.Ике уч арасында шарларны җәю, берничә өлештән торган предметны , берсе өстенә икенчесен куеп төзергә өйрәтү.Пөхтә әвәләү осталыгын ныгыту. | |
| | | **4 атна** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Тема: «Дымка уенчыгы белән танышу. Бизәкләр рәсемләү»**<br>**Максат:** Халыкның дымка уенчыгы белән таныштыру. Якты, матур төсле бизәкләр белән бизәлгән уенчыкны краудан шатлык хисе тудыру. Балаларның игътибарын уенчыкны бизәгән бизәкләргә юнәлтү. Аерым бизәкләрнең элементларын атау һәм төсләрен әйтергә өйрәтү. | | **Тема: «Үзең теләгән уенчыкны кисеп ябыштыр»**<br>**Максат:**Балаларның күзаллавын. иҗадилыгын үстерү. Форма һәм зурлык турында белемнәрен ныгыту. Сүрәтнең өлешләрен дөрес ябыштыру һәм төзү алымнарын күнектерү. |
| **Январь** | | **3 атна** | |
| | **Тема: «Өй- бияләйне бизибез » (театраль күренешләр мотивы буенча)**<br>**Максат:** «Бияләй» әкияте мотивы буенча рәсемләргә өйрәтү.Әкияти образ төзү.Күзаллауны, иҗадилыкны үстерү.Предметны бизәү осталыгын формалаштыру.Рәсемләү процессында төрле төстәге буяулар куллану, башка төрле төскә буяганда пумаланы юу һәм эш беткәч тә пумаланы юып корытып кую күнекмәләрен ныгыту. | **Тема: «Мандариннар һәм әфлисуннар»**<br>**Максат:**Балаларның балчыкны ике уч арасында түгәрәк сыман хәрәкәтләр ясап тәгәрәтү алымнарын ныгыту.Төрле зурлыктагы предметларны әвәләргә өйрәтү. | |
| | | **4 атна** | |
| | **Тема: «Дымка уенчыгы- үрдәкне бизибез»**<br>**Максат:** Балаларны дымка уенчыгы белән таныштыруны дәвам итү.Кәгазьдән киселгән үрдәк уенчыгына бизәк элементларын аерып күрсәтергә өйрәтү. Дымка бизәгенең матурлыгыннан, яктылыгыннан килеп чыккан нәтиҗәдәдән шатлык хисе тудыру. | | **Тема: «Матур салфетка»**<br>**Максат:**Балаларны квадрат формалы кәгазьдә бизәк төзергә өйрәтү.Аның почмакларына һәм уртасына бер төстәге зур түгәрәкләр, ә яннарының уртасына башка төстәге кечкенә түгәрәкләр ябыштырырга. Төсләр үзләштерүен, эстетик хисләр һәм композиция төзү осталыкларын үстерү. |

| Февраль | | 1 атна | |
|---|---|---|---|
| | **Тема: «Без саф һавада кар бабай әвәлибез»**<br>**Максат:**Балаларда шаян кар бабай образын булдыруга теләк тудыру. Түгәрәк формалы предметларны рәсемләүдә күнектерү. Рәсемләүдә берничә өлештән торган предметларны рәсемләргә өйрәтү.Пумаланың барлык төкләрен дә кулланып түгәрәк форманы өзлексез сызыклар белән, өскә аска, уңга сулга буяу осталыкларын ныгыту. | **Тема: « Песи һәм чыпчыклар»**(хәрәкәтле уен мотивы буенча)<br>**Максат:**Әвәләүдә хәрәкәтле уен образын чагылдыру осталыкларын формалаштыруны дәвам итү.Күзаллауны, иҗадилыкны үстерү.Гомуми нәтиҗәне үзләштерүне һәм әвәләүдә уен образын биргәндә алдан өйрәнгән алымнарны ныгыту. | |
| | | **2 атна** | |
| | **Тема: «Кояш яктырта»**<br>**Максат:** Балаларны кояш образын түгәрәктән туры һәм сыгылган нурлар чыккан итеп рәсемләргә өйрәтү. Пумаладан артык суны стакан кырыена сыгып калдыру осталыкларын ныгыту. Темага туры китереп рәсемне тулыландырырга өйрәтү. Иҗадилык һәм мөстәкыйльлекне үстерү. | | **Тема: «Түгәрәктә бизәк»**<br>**Максат:**Түгәрәк кырыена бизәкләрне урнаштырырга өйрәтү. Билгеле бер эзлеклелектә, фигураларны бизәк төзү өен чиратлаштырып кую. ( өстә, аста, сулда, уңда зур түгәрәкләр, ә алар арасында кечкенә түгәрәкләр.Формага җилем сөртү осталыкларын ныгыту.Ритм хисен үстерү. |
| | | **3 атна** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Тема: «Очкычлар оча»**<br>**Максат:** Предметларны берничә өлешле, төрле юнәлештә сызылган сызыклар йөртеп рәсемләү осталыкларын ныгыту.Предмет образын рәсемдә бирергә өйрәтү. Эстетик үзләтерүне үстерү. | **Тема: «Очкычлар аэродромда тора»**<br>**Максат:**Балаларны ике бер төрле формалы өлештән торган озынча балчык кисәгеннән әвәләргә өйрәтү. Бер кисәк балчыкны күз үлчәме белән ике бер төрле кисәккә бүлү, ике уч арасында озынча хәрәкәтләр белән тәгәрәтү, һәм кирәкле формага кергәнче шомарту.Әвәләнгән сүрәткә карап шатлык хисе тудыру. | |
| | | **4 атна** | |
| | **Тема: «Агачлар карда»** (күмәк эш)<br>**Максат:**Балаларны рәсемдә кыш сүрәтен сүрәтләргә өйрәтү. Агачлар рәсемләүдә күнектерү.Пумаланы юу осталыкларын ныгыту.Эстетик үзләштерүне үстерү кисть. | | **Тема: «Әбигә, әнигә бүләккә-чәчәкләр»**<br>**Максат:**Балаларны детальләрдән сүрәт төзергә өйрәтү.Матур әйбер (бүләк) ясауга омтылыш тәрбияләү.Образлы күзаллауны формалаштыру,эстетик үзләштерүне үстерү. |
| **Март** | | **1 атна** | |
| | **Тема: «Җептә матур флагчыклар»**<br>**Максат:** Балаларны турыпочмаклык формасындагы предметларны аерым горизонталь һәм вертикаль сызыклар белән рәсемләргә өйрәтү. Турыпочмаклык формасы белән таныштыру.Төсле карандашлар белән рәсемләү һәм буяу алымнарын камилләштерү. | **Тема: «Курчак, куян, аю өчен сый.»**<br>**Максат:**Үзләренә әвәләргә әлеге уенчыкларны сайлап эчтәлек уйлый белү осталыкларын үстерү. Мөстәкыйльлек тәрбияләү.Әвәләү алымнарын ныгыту.Уен өчен кирәкле нәрсә булса да әвәләүгә теләк формалаштыру. Күзаллауны үстерү. | |
| | | **2 атна** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Тема: «Кем нәрсә тели, шуны матур итеп рәсемли...»**<br>**Максат:** Эстетик үзләштерүне үстерү.Матур предметларны, күренешләрне күрергә һәм аерырга өйрәтү.Үз теләкләре буенча төрле материаллар белән рәсемләү осталыкларын ныгыту. | | **Тема: «Флагчыклар»**<br>**Максат:** Ике өлештән торган турыпочмаклык формасындагы предметларны кисеп ябыштыруда төзү осталыкларын ныгыту.Гомуми нәтиҗәләргә шатлану хисе тәрбияләү. |
| | | **3 атна** | |
| | **Тема: «Китапчыклар»**<br>**Максат:** Балаларны карандашны кәгазьдән аермыйча дүрт почмаклы формалы китапны өскә, аска, уңга, сулга йөртеп рәсемләргә өйрәтү.Балаларның күзаллавын, иҗади сәләтләрен үстерү. | **Тема: «Аумас аю »** (Мишка-неваляшка)<br>**Максат:**Балаларны түгәрәк формалы, зурлыгы буенча төрле булган берничә өлештән торган сүрәтне әвәләүдә күнектерү.Бер-берсенә беркетү алымнарын камилләштерү. | |
| | | **4 атна** | |
| | **Тема: «Турыпочмаклык формасында нәрсә булса да яса»**<br>**Максат:**Алдан өйрәнгән алымнарны кулланып , рәсемләүнең эчтәлеген мөстәкыйль уйлап рәсемләргә өйрәтү.Уйланган рәсем өчен карандаш төсләрен үзләре сайлап куярга өйрәтү. Күзалауны, төсләр хисен үстерү. | | **Тема: « Салфетка»**<br>**Максат:**Квадрат формалы салфеткага түгәрәк һәм квадратлардан бизәк төзергә өйрәтү. Салфетканың почмакларына һәм уртасына түгәрәк формаларын,ә квадрат формаларын алар арасына урнаштыру.Детальләрне пөхтә ябыштыру |
| **Апрель** | | **1 атна** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Тема: «Сыерчык оясы»**<br>**Максат:** Балаларны турыпочмаклык формалы предметны, түгәрәк һәм туры түбәдән торган өлешләрдән рәсемләргә өйрәтү. Буяу алымнарын ныгыту. | **Тема: «Матур кошчык»**<br>**Максат:**Балаларны берничә өлештән торган предмет әвәләргә өйрәтү. Бармак оч белән чеметү алымын ныгыту.Халык уенчыгын үрнәк буенча әвәләргә өйрәтү. | |
| | | **2 атна** | |
| | **Тема: «Төрле төсле кульяулыклар кибәләр»**<br>**Максат:** Квадрат формалы таныш предметларны карандашны кәгазьдән алмыйча гына рәсемләүдә күнектерү.Бер юнәлештә генә пөхтә буяу осталыкларын ныгыту.( өстән-аска контурдан чыкмыйча буяу,сүрәтне тулы биткә урнаштыру) | | **Тема: «Сыерчык оясы»**<br>**Максат:**Балаларны кисеп ябыштыруда берничә өлештән торган предметларны ябыштырырга өйрәтү. Өлешләрнең формаларын ачыклау.Балаларның төсләрне белүен ачыклау.Төсләрне үзләштерүен үстерү. |
| | | **3 атна** | |
| | **Тема: «Матур келәм»**<br>**Максат:** Балаларны төрле характердагы сызыклар белән рәсемләүдә күнектерү.Квадрат формасындагы кәгазьне төрле юнәлештә сызылган, кисешкән төрле төсле сызыклар белән бизәргә өйрәтү. Гомуми нәтиҗәгә уңай эмоциональ халәт булдыру. | **Тема: «Чебиләр саф һавада»**<br>**Максат:**Өлешләрнең формасын, зурлыгын саклап, ике өлештән торган предметларны әвәләү осталыкларын формалаштыруны дәвам итү.Гомуми нәтиҗәгә уңай эмоциональ халәт булдыру. | |
| | | **4 атна** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Тема: «Матур арба»**<br>**Максат:** Берничә өлештән торган турыпочмаклык формалы предметларны сүрәтләү осталыкларын формалаштыруны дәвам итү. Рәсемне буяу белән буяуда күнектерү. Буяу алымнарын ныгыту. Күзаллауны, инициативаны үстерү. | | **Тема: «Лалә»**<br>**Максат:**Балаларны өлешләрдән бербөтен төзергә өйрәтү. Балаларны бакча чәчәкләре һәм аларның өлешләре белән таныштыру. |
| **Май** | | **1 атна** | |
| | **Тема: «Бәйрәм салюты» (бәйрәмнән картина)**<br>**Максат:** Бәйрәмнән алынган тойгыларны рәсемдә чагылдырырга өйрәтүне дәвам итү. Буяулар белән рәсемләүдә күнектерү. Үз рәсемең турында сөйләү теләге үстерү. | **Тема: «Курчак өчен сый»**<br>**Максат:**Алдан өйрәнгән алымнарны ныгыту.Чиста пөхтә эшләүдә күнектерү.Иҗадилыкны, күзаллауны үстерү. | |
| | | **2 атна** | |
| | **Тема: «Болында тузганаклар»**<br>**Максат:** Балаларда чәчәктә утыручы болынны, чәчәк формасының матурлыгын рәсемләргә теләк булдыру.Буяу белән рәсемләү алымнарын камилләштерү. Балаларның күзаллавын, иҗади сәләтләрен үстерү. | | **Тема: «Тиздән бәйрәм җитә»**<br>**Максат:**Балаларны әзер фигуралар белән композиция төзергә өйрәтү.Шарларның һәм флагчыкларның урыннарын мөстәкыйль табуларына ирешү.Өлешләрне ябыштырганда җилемне уртасыннан кырыйга таба сылап, ябыштырган детальне салфетка ярдәмендә тотып ябыштыру.Сүрәтне биткә матур итеп урнаштырырга өйрәтү. Эстетик үзләштерүне үстерү. |
| | | **3 атна** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Тема: «Кулъяулык»**<br>**Максат:** Балаларны горизонталь һәм вертикаль сызыклардан шакмаклы бизәк ясарга өйрәтү.Пумаланы дөрес тотып, кәгазьдән аермыйча сызу хәрәкәтләрен камилләштерү.Кулъяулыкка төсләр ярашын мөстәкыйль сайларга өйрәтү.Балаларның күзаллавын, иҗади сәләтләрен үстерү. | **Тема: «Үзең теләгән хайванны әвәлә»**<br>**Максат:**Балаларның хайван әвәләү осталыкларын ныгыту.Түгәрәк һәм озынча формалы предметларның характерлы билгеләрен төгәл күрсәтеп әвәләргә өйрәтү.Балчык кисәген учта туры һәм түгәрәкләү хәрәкәтләре белән тәгәрәтү алымын камилләштерү. | |
| | | **4 атна** | |
| | **Тема: «Уйлау буенча буяу белән рәсемләү»**<br>**Максат:** Тема сайлаганда мөстәкыйльлекне үстерү.Рәсемләү барышында алдан өйрәнгән осталыкларны кулланып, кирәкле төсләрне файдаланып, иҗадилык элементларын кертеп рәсемләргә өйрәтү. | | **Тема: «Өй»**<br>**Максат:**Берничә өлештән торган сүрәтне билгеле бер эзлеклелекне тотып, альбом битенә дөрес итеп урнаштырырга өйрәтү. Геометрик фигураларны белүләрен ныгыту. |

***Җыр***

***Аңлатма язуы***

«Музыка» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә Һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татар музыкасына карата кызыксыну уяту, аны тыңларга теләк белдерү. Аның хисле-образлы эчтәлеге турында сөйләү, кичерешләр белән бүлешү.

Татар композиторларының музыкаль әсәрләрен тыңлап, музыканың төп өч жанры: «җыр», «бию», «марш» төшенчәләрен бирү. Балаларның музыка характерын, кәефен бирә белү сәләтләрен үстерү.

Музыка уен кораллары (курай, кубыз, тальян гармун һ. б.) һәм аларның яңгырашы белән танышуны дәвам итү. Татар җырларын дөрес, сәнгатьле итеп һәм аңлап башкарырга, сүзләрен ачык итеп әйтергә күнектерү.

Татар биюенә хас гади хәрәкәтләр («аяк очларында атлап йөрү», «чүгү», «аяк очларында күтәрелү», «берле бишек», «баш-үкчә», «култыклашып әйләнү», «борма» (гади вариант) һ. б.) белән таныштыруны дәвам итү.

Музыка характерына туры китереп, ритмлы хәрәкәтләр башкаруны формалаштыру.

Хәрәкәтле импровизацияләрдә музыкаль образны чагылдырырга омтылуны хуплау, балалар белән бергә гәүдәләнеш вариантларын («тәкәббер» әтәч, «кайгыртучан» тавыклар, тик-тормас чебиләр һ. б.) тикшерү, музыкаль әкият эчтәлеге һәм характерына дөресрәк туры килә торган образны сайларга булышу, һәр иҗади табышны хуплау.

Балалар эшчәнлегенең төрле структурасына музыка өстәү; матур әдәбият, сынлы һәм театр сәнгатьләре әсәрләрен файдаланып, кәефкә туры килерлек һәм хис-кичерешләргә ярдәм итәрлек музыка астында.

## 2.5 «ФИЗИК ҮСЕШ»

***СӘЛАМӘТЛЕК***

***Аңлатма язуы***

Һәр көнне 5-6 минутлык иртәнге гимнастика үткәрү.

Һавада йөргәндә хәрәкәтле күмәк уеннарда һәм физик күнегүләрдә һәм физик күнегүләрдә катнашырга, шөгыльләрдән тыш вакытларда физкультура җиһазларыннан файдаланырга өйрәтү.

Чаңгыда йөрергә, таудан чана шуарга.Шартлар булган очракта балаларны коендыруны оештыру.

Айга бер мәртәбә, 15-20 минутлык хәрәкәтле ял вакыты оештыру.

Физик күнегүләр белән кызыксыну тәрбияләү.

Физик сыйфатларны үстерү(тизлек,көч, сыгылучанлык,түземлелек, тигезлекне саклау). Балаларда физик камиллекнең, хәрәкәт активлыгының хаҗәтен аңлауны формалаштыру.

**ЙОКЫДАН УЯНУ ГИМНАСТИКАСЫ**

**Комплекслы-тематик план**

| **ай** | **гимнастика** |
|---|---|
| сентябрь | «Уяну»<br>Йокы качты тәрәзәдән, йөгерде юллардан,<br>Ә без синен белән уяндык, уяндык та елмайдык (киерелү)<br>Башта күзләрнен берсен ачтык, аннары икенчесен,<br>Кулларны күтәреп төшердек, велосипед әйләндердек.<br>Уңга-сулга борылдык, аннары сикереп тордык. |
| октябрь | «Хәерле иртә»<br>Хәерле иртә, күзләр. Сез уяндыгызмы?(күзләргә массаж. Бармаклар белән бинокль ясап, як-якка карыйлар)<br>Хәерле иртә, колаклар. Сез уяндыгызмы?(колакларга массаж. Учны колакларга куялар (“Чебурашка”), як-якны тыңлыйлар)<br>Хәерле иртә, куллар. Сез уяндыгызмы?(кулларның башта берсенә, аннан икенчесенә массаж. “Пропеллер” күнегүе)<br>Хәерле иртә, аяклар. Сез уяндыгызмы?( аякларның башта берсенә, аннан икенчесенә массаж. “Велосипед” күнегүе)<br>Хәерле иртә, кояш. Мин уяндым!( кулларны сузып киерелү) |
| ноябрь | Әйдәгез, бергәләп, басабыз,<br>Кулларны ян – якка сузабыз.<br>Аннары бөгеләбез,бергәләп тураябыз. |

| | |
|---|---|
| | Кулларны күтәрәбез,<br>Кояшка сәлам юллыйбыз.<br>Кулларны качырабыз,<br>Аннары аларны бергәләп эзлибез.<br>Уңга карыйк,<br>Сулга борылыйк.<br>Утырабыз, торабыз.<br>Үкчәгә дә басабыз,<br>Аяк очларына басып,<br>Кояшка үреләбез. |
| декабрь | «Без шулай итәбез»<br>Без йоклап тордык, бераз уйнарга булдык.<br>Башны иябез алга, уңга, сулга борабыз,<br>Аннан карап торабыз.<br>Иң өсләрен сикертәбез, кулларны биетәбез.<br>Бер алга, бер артка сузып,<br>Күңелле ял итәбез.<br>Аннары без чүгәлибез, тезләрне кочаклыйбыз.<br>Башны алга яшереп, без ападан качабыз. |
| январь | «Пескәй »<br>1. “Пескәй уяна”. Ятып, бергә уң аякны һәм сул кулны күтәрәләр, төшерәләр. Аннан сул аякны һәм уң кулны күтәрәләр, төшерәләр. Аннан 2 кулны һәм 2 аякны бергә күтәрәләр, төшерәләр. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>2. «Пескәй сөенә». Үрмәләү позасына керергә. Башны күтәрергә, умыртка сөяген бөгәргә. Тирән сулыш алырга. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>3.«Пескәй ачулана». Үрмәләү позасына керергә. Иякне күкрәккә тидерергә, арканы бөгәргә. Тирән сулыш алырга. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>4. “Пескәй сузыла” Сузылу күнегүе.<br>5. “Пескәй сикерә” Сикерү. |
| февраль | “Чәчәк”<br>Чәчәк йоклый,<br>Чәчәк уяна. (киерелү күнегүләре)<br>Иртәнге кояшка<br>Ул бик куана. (урында сикерү)<br>Кояшка сузыла (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Кояшка үрелә (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Күбәләк дустына (кулларны канатлар каккан кебек җилпиләр) |

| | |
|---|---|
| | Сәлам өләшә (сәлам бирәләр) |
| март | Без уяндык, (киерелү күнегүләре)<br>Күзләрне ачтык, (күзләрен ачалар)<br>Аякларны суздык (аякларын сузып, селкетәләр)<br>Аларны да уяттык!<br>Ян –якка борылып (басып, ян –якка борылалар)<br>Кояшка без карадык. (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Якты көнгә сокланып,<br>Матур итеп елмайдык. (ян – якка борылып, елмаялар)<br>Сикереп тә алдык (сикерү күнегүләре)<br>Йөгердек тә (урында йөгерү)<br>Хәзер инде без<br>Уйнарга бергә әзер! (үз-үзеңне кочу) |
| апрель | Аякларың тыпырдат (аякларны тыпырдаталар)<br>Кулларыңны чәбәклә.(кулларны чәбәклиләр)<br>Бер монда, бер монда,<br>Кыен эш түгел бер дә. (ян-якка борылып кулларны чәбәклиләр)<br>Башың аска иеп ал, (башларын бер иеп, бер күтәрәләр)<br>Кулларыңны болгап ал. (йөзү күнегүләре)<br>Бер монда, бер монда,<br>Кулларыңны болгап ал.(ян- якка борылып, йөзү күнегүләре эшлиләр)<br>Бу дустың белән күреш, (уңга борылып, сәләм юллыйлар, елмаялар)<br>Бу дустың белән күреш.(сулга борылып, сәләм юллыйлар, елмаялар)<br>Йә иптәш, йә, әйлән, (урында сикереп, әйләнәләр)<br>Бик кыен түгел бу эш. |
| май | Нәниләр бара тигез юл буйлап. (урында атлыйлар)<br>Тигез юл буйлап, ашыкмый атлап. (урында атлыйлар)<br>Зур-зур ташларны<br>Сикереп үтәләр. (урында сикерәләр)<br>Уңга да баралар, сулга да баралар, (уңга – сулга борылу күнегүләре)<br>Су аша йөзеп, (йөзү күнегүләре)<br>ярга чыгалар. (сулыш алу күнегәләре) |

**Саф һавада хәрәкәтле уеннар**

Хәрәкәтле уеннар балаларның физик үсешенә булыша, сәламәтлекләрен ныгыта, хәрәкәт координациясен яхшырта. Әлеге уеннар ярдәмендә бала тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсә. Бу уеннарны уйнаганда билгеле бер кагыйдәләрнең үтәлү мәҗбүрилеге балаларны тәртипкә, үз эш

гамәлләр, хәрәкәтләрен барларга өйрәтә. Уенның шартларын истә калдыру аша балаларда күзәтүчәнлек тәрбияләнә, истә калдыру сәләте, хәтер эшчәнлеге яхшыра. Уен бапрышанда балалар бергәләп уйнау, хәрәкәт итү, ситуацияне хәл итү кебек күнекмәләргә өйрәнәләр, башка балалар арасында үзеңне тоту, гомуми кагыйдәләргә буйсыну кебек тәртип кагыйдәләрен үзләштерәләр.

**Комплексы-тематик план**

| Ай | Атна | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | «Аю өне янында» «Бүре һәм куяннар» | Сикерү күнекмәләрен үстерү, сыгынучанлыкны, җитезлекне булдыру, сиганал буенча хәрәкәтләрне төгәл башкарырга өйрәтү. |
| | II | «Светофор һәм автомобиль» | Бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. Юлдагы куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. |
| | | «Трамвай” | Игътибарлыкларын тупларга күнектерү, түземлек тәрбияләү, уен кагыйдәсен үтәргә өйрәтү. |
| | III | «Огуречик» “Көтүче һәм көтү” | Йөгерү тизлеген үстерү,сигнал буенча хәрәкәт итү,шигырь сүзләренә туры китереп уйнау, күзәтүчәнлекне үстерү. |
| | IV | «Песи һәм тычканнар», | Пространствода ориентлашу, бәрелми – төртелми уйнауны булдыру. |
| | | “Очкычлар” | Төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен системалаштыру, дус –тату уйнауны булдыру. |
| Октябрь | I | “Ябалак” | Игътибарлылык, кыюлык, җитезлек кебек матур сыйфатлар тәрбияләү, шигырь сүзләренә туры китереп уйнау. |
| | | “Төсле автомобильләр” | Юл йөрү кагыйдәләрен ныгыту, төсләр турында белемнәрен камилләштерү, сиганал буенча хәрәкәтләнүне булдыру |
| | II | «Кыршау эченә ыргыт» | Дус – тату уйнауны булдыру, туп ырггыту, төгәллек сыйфатлары тәрбияләү |
| | | “Инеш аша сикереп чык” | Урыннан 2 аякта ераклыкка сикерү күнекмәләрен камилләштерү, кыюлык тәрбияләү |
| | III | «Бау аша сикер», | Сикерү күнекмәләрен камилләштерү, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| | | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту. |
| | IV | “Төсле автомибильләр” | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |
| | | “Аю-бүре” | Йөгереклек һәм җитезлек сәләтен үстерү,сүзләргә туры китереп хәрәкәтләр ясау. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ноябрь | I | “Казлар - аккошлар” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | “Сиздермичә йөгереп үт” | Сизгерлек булдыру, дус –тату унарга өйрәтүне дәвам итү. |
| | II | «Төлке һәм тавыклар», | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү. |
| | | “Үз төсеңне тап” | Хәтерне, җитезлекне үстерү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга өйрәтүне дәвам итү, кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| | III | «Мин качам, син тот», | Коллективта бергә уйнау теләге уяту, пространствода ориентлашу булдыру, сигналларга игътибар итү, ишетү сәләтен үстерү. |
| | | «Светофор һәм автомобиль» | Бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. Юлдагы куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. |
| | IV | «Аучылар һәм куяннар» | Тупны ыргытырга,дус һәм тату уйнарга өйрәтү, җитезлекне үстерү. |
| | | “Әбәкле” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| декабрь | I | “Песи һәм кошчыклар” | Хәрәкәт координациясен, җитезлекнее үстерү, уен белән кызыксындыру булдыру. |
| | | «Кемдә йөзек?» | Халык уеннарына карата кызыксыну уяту, хәрәкәт активлыгын үстерү. |
| | II | “Кем беренче?” | Йөгерү тизлеген үстерү, максатка ирешүчәнлек кебек яхшы сыйфатлар тәрбияләү. |
| | | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү |
| | III | «Куяннар һәм төлке» | Сабырлык, җитезлек, хәрәкәт активлыгы тәрбияләү, пространствода оринтлашу булдыру, рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен үстерү. |
| | | “Кегляны аудар” | Төзлекне, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |
| | IV | «Балалар һәм әтәч» | Җитезлекләрен үстерү, бер –бер артлы йөгерү күнекмәләрен булдыру. |
| | | “Тавык кетәклегендә төлке” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү. |
| ян ва | I | «Куяннар һәм төлке” | Сабырлык, җитезлек, хәрәкәт активлыгы тәрбияләү, пространствода оринтлашу булдыру, рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен үстеру |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Кем беренче?” | Йогерү тизлеген үстерү, максатка ирешү сыйфатын тәрбияләү. |
| | II | “Энә һәм җеп” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, бер-бер артлы йөгерү күнекмәләрен үстерү. |
| | | “Бүре һәм сакрыклар” | Түгәрәккә басарга, күмәк уйнарга, хәрәкәтләрне дөрес итеп башкарырга күнектерүне дәвам итү. |
| | III | “Оядагы кошлар” | Сизгерлек, сигнал буенча хәрәкәт итү күнекмәләрен тәрбияләү. |
| | | “Үз парыңны тап” | Төрле юнәлештә йөгереп, сигнал булгач, үз парыңны табу күнекмәләрен үстерү, дус – тату уйнауны булдыруны дәвам итү. |
| | IV | “Кем беренче?” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| февраль | I | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү. |
| | | “Кегляны аудар” | Төзлекне, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |
| | II | “Төлке килә” | Сигнал буенча хәрәкәтләнү күнекмәләрен камилләштерү, сизгерлекләрен үстерү. |
| | | «Ак, димә, кара, димә» | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | III | “Чаналар белән ярыш” | Җитезлекне, тизлекне булдыруны дәвам итү, дус –тату уйнау теләкләре тудыру. |
| | | “Соры бүре” | Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру. |
| | IV | “Кошлар очалар” | Хәрәкәт тизлеген үстерүне дәвам итү, төрле юнәлештә очу күнегүләрен башкарып йөгерү, сигналларга игътибар итүне булдыру. |
| | | «Эстафета» | Йөгерү тизлеген үстерүне дәвам итү, бер – бер артлы сигнал буенча йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| март | I | «Тупны ыргыт» | Төзлекне, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |
| | | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| | II | “Инеш аша сикереп чык” | Урыннан 2 аякта ераклыкка сикерү күнекмәләрен камилләштерү, кыюлык тәрбияләү. |
| | | “Үрдәк атыш” | Тупны тотарга, туптан качарга өйрәтүне дәвам итү, төз атуны булдыру, балаларның хәрәкәтчәнлекләрен, җитезлекләрен үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | «Кармак» | Сикерү күнекмәләрен үстерү, сыгынучанлык, чыдамлылык булдыру, бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | | «Буяучы һәм буяулар», | Йөгерү тизлеген үстерү, пространствода ориентлашу күнекмәләрен, төсләр турында белемнәрен камилләштерүне дәвам итү. |
| | IV | "Үз парыңны тап" | Төрле юнәлештә йөгереп, сигнал булгач, үз парыңны табу күнекмәләрен үстерү, дус – тату уйнауны булдыруны дәвам итү. |
| | | "Кармак" | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| апрель | I | "Бүре һәм сакрыклар" | Түгәрәккә басарга, күмәк уйнарга, хәрәкәтләрне дөрес итеп башкарырга күнектерүне дәвам итү. |
| | | "Тупны тәгәрәт" | Тупны предметлар аша тәгәрәтү, максатка ирешүчәнлек, башлаган эшне азагына кадәр эшләп чыгу күнекмәләрен үстерү. |
| | II | "Чиләп белән бакалар" | Сикерү тизлеген үстерү, сигнал буенча хәрәкәт итү, пространствода ориентлашу, тизлек булдыруны дәвам итү. |
| | | "Флагка кадәр йөгер" | Йөгерү тизлеген үстерүне дәвам итү, бер – бер артлы сигнал буенча йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | "Тавык кетәклегендә төлке" | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү өстендә эшне дәвам итү. |
| | | "Әбәк" | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | IV | "Бал кортлары" | Йөгерү күнекмәләрен үстерүне дәвам итү, пространствода ориентлашуны камилләштерү. |
| | | «Идәндә калма», | Сикерү күнекмәләрен камилләштерү, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| май | I | «Каршылыклар юлы» | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |
| | | "Тупны, сикертеп, алып бар" | Тупны сикертеп алып барырга өйрәтә башлау, максатчанлык, батырлык сыйфатлары тәрбияләү. |
| | II | «Трамвай" | Игътибарлыкларын тупларга күнектерү, түземлек тәрбияләү, уен кагыйдәсен үтәргә өйрәтү. |
| | | "Буш урын" | Күзәтүчәнлекләрен, игътибарлыкларын үстерү, этешми-төртешми уйнау күнекмәләрен камилләштерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | “Бал кортлары” | Йөгерү күнекмәләрен тәрбияләү. |
| | | «Кем тизрәк?» | Төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен системалаштыру, дус –тату уйнауны булдыру. |
| | IV | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| | | “Соры бүре” | Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру. |

***3.Оештыру бүлеге***

3.1. Төркемдә көндәлек режим балаларның яшь үзенчәлекләре һәм СанПин таләпләренә туры китереп төзелгән

| № | Режим моментлары | Үтәү вакыты |
|---|---|---|
| **1.** | Балаларны кабул итү. Иртәнге фильтр.Уеннар. | 6.00-7.30 |
| **2.** | Иртәнге гимнастика. | 7.30-7.35 |
| **3.** | Иртәнге ашка әзерлек. | 7.35-7.45 |
| **4.** | Иртәнге аш. | 7.45-8.05 |
| **5.** | Белем бирү эшчәнлегенә әзерлек. | 8.05 - 8.30 |
| **6.** | Белем биру эшчәнлеге | 1)8.30-8.45 2)8.55-9.10 (дүшәмбе 10.50-11.05 (урамда), сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга 15.15-15.30) |
| **7.** | Уеннар. Икенче иртәнге аш.Урамга чыгарга әзерлек. | 9.10-9.40 (дүшәмбе 8.45-9.40) |
| **8.** | Урамда булу. | 9.40-11.25 |
| **9** | Урамнан керү. Көндезге ашка эзерлек. | 11.25-11.45 |
| **10** | Көндезге аш. | 11.45-12.05 |
| **11** | Көндезге йокыга әзерлек. Көндезге йокы. | 12.05-14.40 |
| **12.** | Йокыдан тору. Чыныктыру чаралары. | 14.40-15.00 |
| **13.** | Төштән соңгы аш. | 15.00-15.15 |
| **14.** | Уеннар.Мөстәкыйл эшчәнлек. Түгәрәк эшчәнлеге. | 15.15-16.10 сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга 15.15-15.30) |
| **15.** | Уеннар.Кичке ашка әзерлек. | 16.10-16.25 |
| **16.** | Кичке аш. | 16.25-16.45 |

| 17. | Уеннар.Урамда мөстәкыйль уеннар. Өйләренә озату. | 16.45-18.00 |
|---|---|---|

**3.2 Оештырылган белем бирү эшчәнлеге**

4 нчы төркем Н.Е. Вераксы, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясе астындагы "От рождения до школы" программасы буенча эшли. Бу программа ФГОС таләпләренә туры китереп төзелгән. Шушы программадан чыгып төркемдә белем эшчәнлегенең атналык тематикасы төзелде:

| № | Проектның (блокның) темасы,максаты, бурычлары | Үтәү вакыты | Йомгаклау чарасы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Сау бул җәй, исәнме балалар бакчасы!» | 31 -29 август | «Уенчыклар» (уен-шөгыль) |
| 2 | «Безнең балалар бакчасы» | 2-6сентябрь | «Без бакчабызны яратабыз» (балалар бакчасы турында җырлар җырлау һәм тыңлау) |
| 3 | «Минем өем, минем шәһәрем» | 9-13сентябрь | «Түбән Кама» (рәсемнәр карау) |
| 4 | Мониторинг | 16 -27 сентябрь | Диагностик карталарнытутыру. |
| 5 | «Исәнме көз!» | 30 нчы сентябрь – 11 нчеоктябрь | Рәсем "Төрле төстәге куыклар" |
| 6 | «Коз» | 14 нче октябрь -1 нче ноябрь | "Тәлинкәдә зур һәм кечкенә алмалар" ябыштыру |
| 7 | «Халыкбердэмлеге коне» | 5-8 ноябрь | Презентация карау. |
| 8 | «Жэнлеклэрничеккышкаэзерлэнэ» | 11-15 ноябрь | Рэсем "Урманда кем яши" |
| 9 | «Савытсаба» | 18-22 ноябрь | "Кунак каршылыйбыз" –уен. |
| 10 | «Әниләр көне» | 25-29ноябр | Бүләкләр ясау (открыткалар) |
| 11 | Мәрхәмәтлек атнасы | 2-6 декабрь | Бүләкләр ясау (открыткалар,сувенирлар) |
| 12 | Менә салкыннар килде һәм кыш җитте | 9-13 декабрь | Рәсем "Чыршыкай" |
| 13 | «Яңа ел!» | 16-31 декабрь | Яңа ел кичәсенә җырлар өйрәнү. |
| 14 | «Мин һәм минем сәламәтлегем» | 8 – 10 гыйнвар | Әвәләү "Мандариннар һәм әфлисуннар" |
| 15 | «Кыш»<br>. | 13-24 гыйнвар | Өй биялэйне бизибез -рәсем |
| 16 | Салкын кайда яши? | 27 нче гыйнвар-7 нче феврал | "матур салфетка ябыштыру |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 17 | «Татар халык культурасы һәм традицияләре белән таныштыру» | 10-20февраль | «Чак-чак» (әвәләү) |
| 18 | «Ватаннысаклаучыларкөне» | 25 -28февраль | «Бабайларны, әтиләрне, малайларны бәйрәм белән котлыйбыз» (бүләкләр бирү) |
| 19 | «8 нче март Халыкара хатын-кызлар көне» | 2 -13 март | Энилэргэ бүләкләр ясау (открыткалар, сувенирлар) |
| 20 | «Яз» | 16-27март | 5. Яз турында җырлар җырлау һәм тыңлау |
| 21 | «Бөтеньдөньясәламәтлеккөне» | 30 нчы март–10 нчыапрел | Матур кошчык әвәләү |
| 22 | Мониторинг | 13-24 апрель | Диагностик карталарнытутыру |
| 23 | «Тынычлык, хезмәт, май» (яз һәм хезмәт бәйрәме) | 27нче апрель – 1нче май | Ябыштыру Лалә |
| 24 | «Җиңү көне» | 6 -8май | «Бәйрәм салюты» (рәсем ясау) |
| 25 | «Халыкара гаилә көне» | 11-15нчы май | «Фотолар күргәзмәсе» (әңгәмә-шөгыль) |
| 26 | «Кызыл, сары, яшел» (ЮЙК) | 18-22май | Светофор ябыштыру |
| 27 | «Минем яраткан китапларым» | 25-29май | Әкиятләр, шигырьләр, хикәяләр, (табышмаклар, такмаклар белән таныштыру. |
| 28 | Җәй | 1 нче июнь – 20 нче август | |

3.3. ФГОС таләпләренә туры китереп оештырылган **белем бирү өлкәләре** түбәндәгечә:

| **Организованная образовательная деятельность** | | |
|---|---|---|
| **Базовый вид деятельности** | **Периодичность** | **Примечания** |
| Физическая культура в помещении | 2 | |
| Познавательное развитие | 2 | ФЭМП – 1, Ознакомление с окружающим – 1 |

| | | |
|---|---|---|
| Речевое развитие | 1 | |
| Музыка | 2 | |
| Рисование | 1 | |
| Лепка | 1 раз в 2недели | Чередуется с аппликацией |
| Аппликация | 1 раз в 2недели | Чередуется с лепкой |
| | | |
| Итого | 10 | |
| **Часть, формируемая участниками педагогического процесса** | **Периодичность** | **Примечания** |
| Дополнительное образование | 1 | по запросам родителей |
| Итого | 11 | |
| **Образовательная деятельность в ходе режимных моментов** | | |
| Утренняя гимнастика | Ежедневно | |
| Физическая культура на прогулке | 1 | |
| Комплексы закаливающих процедур | Ежедневно | Утренняя гимнастика<br>Умывание в течении дня<br>Ходьба по корригирующим дорожкам.<br>Воздушные ванны. Ходьба босиком.<br>Постепенный подъем, профилактические физкультурно-оздоровительные процедуры |
| Гигиенические процедуры, формирование КГН | Ежедневно | |
| Утренний круг | Ежедневно | Проводится в форме развивающего общения (развивающего диалога). |
| Вечерний круг | Ежедневно | Проводится в форме рефлексии — обсуждения с детьми наиболее важных моментов прошедшего дня |
| Конструктивно-модельная деятельность | 1р. в неделю | |
| Ситуативные беседы при проведении режимных моментов | Ежедневно | |
| Чтение художественной литературы | Ежедневно | |
| Дежурства | Ежедневно | Со 2 половины учебного года |
| Прогулки | Ежедневно | |

| **Самостоятельная деятельность детей** | | |
|---|---|---|
| Свободная игра | Ежедневно | |
| Самостоятельная деятельность детей в центрах активности | Ежедневно | |

3.4 ФГОС таләпләренә туры килгән белем өлкәләреннән чыгып, балаларның яшь үзенчәлекләре һәм СанПин таләпләренә туры китереп, **атналык оештырылган белем бирү эшчәнлеге** төзелде

| | |
|---|---|
| **Дүшәмбе** | 1. Сөйләм үстерү 08.30-08.45<br>2. Физкультура (у) 10.50-11.05<br>Төзү (режим вакытында) 15.20-15.35 |
| **Сишәмбе** | 1. ФЭМП 08.30-08.45<br>2. Музыка 15.15-15.30 |
| **Чәршәмбе** | 1. Тирә-юнь белән таныштыру 08.30-08.45<br>2. Физкультура 15.15-15.30 |
| **Пәнҗешәмбе** | 1. Әвәләү/ябыштыру 08.30-08.45<br>2. Музыка 15.15-15.30 |
| **Җомга** | 1. Рәсем 08.30-08.45<br>2. Физкультура 15.15-15.30 |

### *3.5 ӘТИ – ӘНИЛӘР БЕЛӘН ЭШ*

Хәзерге фән һәм практика баланың шәхесен формалаштыруда гаиләнең уникаль роль уйнавын исбат итә. Беренче социальләшү гаиләдә башлана, баланың дөньяга, үзенә, башка кешеләргә карашы, мөнәсәбәте формалаша. Ата-аналарның кайгыртучанлыгы балада аның үз-үзенә ышанычын тудыра, башка кешеләр белән түземлек, үзара хөрмәт принциплары нигезендә үзара мөнәсәбәткә керергә әзер торырга ярдәм итә.Ата-ананың тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегендә катнашу мөмкинлеге булу бик зур әһәмияткә ия. Хәзерге заман балалар бакчасы ата-аналарга психологик һәм педагогик ярдәм күрсәтүче учреждение буларак та хезмәт итә. Шул ук вакытта гаилә дә үзара хезмәттәшлек итәр өчен педагогларны өзлексез үсешкә рухландыра. Түбәндәге бурычларны үтәмичә, максатка ирешү мөмкин түгел:

-гаилә белән партнерлык мөнәсәбәте урнаштыру; -бакчада ата-анага бала тормышында катнашу өчен шартлар тудыру;

• бала тәрбияләүдә ата-аналарга психологик ярдәм күрсәтү;

гаиләләр белән үзара аралашуда педагогик компетентлыкны өзлексез күтәрү. Ата-аналар белән үзара бәйләнеш формалары.

1.<u>Мәгълүмати чаралар</u> -(телдән журнал, реклама буклеты; балаларга тәрбия һәм белем бирү сораулары буенча мәгълүмати белешмә хезмәте; СМИ да чыгышлар; мәгълүмати кәрзиннәр, хатлар; күрсәтмә психо-педагогик пропаганда һ.б.)

2. <u>Оештыру эшләре</u>- (ата-аналар җыелышы; анкеталар тутыру; җәмгыяти ата- аналар оешмаларын төзү; коференцияләр, ата-аналар белән берлектә педсоветлар; брифинглар һ.б.)

3 <u>.Культура-агарту чаралары</u> - (ата-аналар мәктәбе; консультацияләр; тематик очрашулар; матур әдәбият буенча тематик күргәзмәләр оештыру; тренинглар; семинарлар; әңгәмә; дискуссияләр; ата-аналар кунакханәсе; түгәрәк өстәл һ.б.)

4. <u>Оештыру-эшчәнлек</u> - (ата-аналар белән берлектә үткәрелгән балаларның үсеш мониторингы, берләштерелгән ата-ана-бала проекты; күргәзмәләр; вернисажлар; мастер-класслар; балалар, педагоглар, ата-аналар

иҗаты; гаилә портфолиосы ясау; иҗади эшчәнлек өчен табигый һәм ташландык материаллар җыю; балалар бакчасын ремонтлауда һәм яшелләндерүдә катнашу; балаларның бакчадагы тормышын сурәтләгән буклет, видеофильмнар әзерләү, журналлар чыгару;бакчада үткәрелгән чаралар турында фотоматериалларны электрон җибәрүдә булышу; үстерешле предметлы тирәлекнең сыйфатын тикшерүдә катнашу һ.б.)

5. <u>Ата-аналарның педагогик процесста катнашуы</u> - (ата-аналар катнашы белән шөгыльләр; балаларга әкиятләр уку; балалар белән төрле темага әңгәмәләр кору; ата-аналар катнашы белән сәхнәләштерү; саф һавада йөргәндә, экскурсияләргә барган балаларны озату; Ачык ишекләр, Сәламәтлек көнендә, Шәфкатьлелек марафонында катнашу һ.б.)

Гаилә белән үзара бәйләнеш буенча эшләү планы.

Максат: педагоглар, ата-аналарның берләшүе һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларның ориентлашу кыймматләре формалашуга бердәм юнәлешен булдыру.

Сентябрь

- Ата-аналар белән оештыру җыелышы уздыру.
- Ата-аналардан “Әйдәгез танышабыз” дип аталган анкета тутырту.
- Ата-аналар өчен педпгог-психолог, шәфкать туташының киңәшләре тупланган төрле папкалар булдыру.
- Тәрәзәләрне җылыту, ябыштыруда ярдәм итүләрен сорау.
- Туган көннәр (сентябрь аенда туучы балаларны котлау оештыру).
- Физкультура ТББЭ-өчен форма булдыру.

Октябрь

- Ата-аналарның сораулары, киңәшләре өчен почта тартмасы булдыру.
- Уен мәйданчыгында төзекләндерү эшләре оештыру.
- ”Көз” бәйрәменә әзерләнү, костюмнар тегү, әзерләү.
- Көзге яфраклардан композиция ясау( әти-әниләр балалар белән берлектә).
- ”Оста куллар” күргәзмәсе оештыру.
- Туган көннәр белән котлау.

Ноябрь

- Мәгълүмәтләр тактасында төрле белешмәләр урнаштыру.
- Әниләр көне оештыру.
- ”Минем әнием”- фотокүргәзмә оештыру.
- Туган көннәр белән котлау.
- Роберт Миңнуллин шигырьләрен уку бәйгесенә катнашуга әзерлек.

Декабрь

- Мәгълүмәтләр тактасында файдалы киңәшләр урнаштыру .
- Уен мәйданчыгында тау ясау өчен карларны җыеп өю.
- ”Чыршы” бәйрәменә әзерлек оештыру.
- Төркемне бәйрәмчә бизәү.
- Әти-әниләр белән бергә эшләнгән балалар эшләреннән күргәзмә оештыру.

Январь

- “Кышкы уеннар”- фотокүргәзмә оештыру.
- Уен мәйданчыгында тау ясау, катыру.
- Кошлар өчен җимлекләр элү.
- Туган көннәр белән котлау.

Февраль

- “Бала тәрбияләүдә әти кешенең роле” темасына белешмә бирү.
- “Әтием- горурлыгым”- фотокүргәзмә.
- Кошлар өчен җимнәр булдыру.
- Туган көннәр белән котлау.

Март

- Ата-аналар өчен педагог- психолог, шәфкать туташының киңәшләре тупланган папкаларны тулыландыру.
- Консультация: “Нокталы массаж”.
- Әти-әниләр белән бергәләп эшләгән кул эшләреннән күргәзмә оештыру.
- 8 Март-халыкара хатын-кызлар көненә багышланган кичәгә әзерлек.
- Туган көннәр белән тәбрикләү.

Апрель

- Белешмәләр тактасында яз турында мәгълүмәтләр бирү.
- Кошлар өчен оялар ясау.”Иң яхшы кош оясы”- бәйге оештыру.

- “Яз” бәйрәменә әзерлек- костюмнар әзерләү, җыр һәм шигырьләр өйрәтү.
- “Ачык ишекләр” көне үткәрү.
- Туган көннәр белән тәбрикләү.

Май

- Уен мәйданчыгында төзекләндерү, буяу эшләре башкару.
- Ата-аналар өчен педагог-психолог, шәфкать туташының киңәшләре тупланган папкаларны тулыландыру.
- “Балалар безнең киләчәгебез”-фотокүргәзмә.
- Туган көннәр белән тәбрикләү.

***КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ:***

***Төп программалар:***


1. Комплекслы программа «Туганнан мәктәпкә кадәр»Веракса Н.Е., Комарова Т.С., Васильева М.А.
2. 64 нче "Сөембикә" балалар бакчасының төп белем бирү программасы.

Парциаль программалар:

1.Балалар бакчасы: Әти-әниләр һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен уку китабы.-Казан:Раннур, 2003.

2. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти – әниләр өчен хрестоматия. – Казан: РИЦ,2011. – 560 б.

3. Белем һәм тәрбия эшчәнлегенең перспектив программасы «туганнан мәктәпкә кадәр» Н.Е. Веракса, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Уртанчылар төркеме.

4. Бондаренко Т.М.Балалар бакчасында физик-сәламәтләндерү эше - Воронеж: ИП Лакоценина Н.А.,2012

5. Закирова К.В., Мортазина Л.Р. "Әй уйныйбыз,уйныйбыз..."Балалар бакчасында хәрәкәтле уеннар:балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма. –Казан:Беренче полиграфия компаниясе,2013. – 224 б.

6. Закирова К.В. "Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе:методик кулланма/К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова, Г.М.Сафиуллина – Казан:Беренче полиграфия компаниясе,2013.-424 б.

7. Зарипова З.М. "Үстерешле уеннар:методик кулланма/З.М.Зарипова , Р.С.Исаева.-Казан:Беренче полиграфия компаниясе,2013.-128 б.

8. Закирова К.В. "Әхлак нигезе-матру гадәт"(Гаиләдә һәм балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбияләү):Методик кулланма/К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова.-Казан:Мәгариф,2004.-383б.

9. Закирова К.В., Мортазина Л.Р.Балачак-уйнап-көлеп үсәр чак: методик кулланма.-Казан: Редакционно-издательский центр,2012

10. Күзәтүләр нигезендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларга әйләнә-тирә турында белем бирү.Нәҗметдинова Р.Ф

11. Комарова Т.С. "Занятия по изобразительной деятельности в детском саду» (Из опыта работы) . М., «Просвещение», 1978.

12.Комплекслы белем бирү «туганнан мәктәпкә кадәр» Н.Е.Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева. Уртанчылар төркеме - Волгоград:Учитель,2012Колесникова Е.В. «Математика для детей 4-5 лет», ФГОС таләпләренә туры килгән.

13. Кравченко И.В., Долгова Т.Л. балалар бакчасында күзәтү. Уртанчылар төркеме. Прогулки в детском саду. Методик кулланма – М.: ТЦ Сфера, 2011.

14. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны юлларда үзләрен хәвефсез тоту кагыйдәләренә өйрәтү дәресләре циклы. Методик күрсәтмәләр/ Авт.-төз.: Г.А.Галеева һ.б.-Казан:"Балаларның тормыш иминлеге фәнни үзәге"ДУ нәшрияте, 2010

15. "Туган телдә сөйләшәбез":методик әсбап/Ф.В.Хәзрәтова,З.Г.Шәрәфетдинова,И.Ж.Хәбибулина.-Казан:Инновацион технологияләр үзәге.-2013.-256 б.

16. Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы.-РИЦ, 2012

17. Хрестоматия для дошкольников 4-5 лет/Сост. Н.П.Ильчук и др.-1-е издание.М., АСТ, 1997.

18. Юсупов Ф.Ю., Камалова З.Ф., Борһанова Р.А. "Тәлбакча".Балалар бакчалары өчен хрестоматия.1990